ЯКЫНАЯ АРАЛАР

Быел Татарстанда юл төзелешенә моңарчы күрелмәгән сумма – 250 миллиард сум акча бүлеп бирелде

> 2

МИЛЛӘТТӘШЛӘР

Үз һөнәрчеләре, үз кәсепчеләре бар Бәрәңгенең. Бер дә аптырап тормыйлар

> 5

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

Песи баласы, бер үз итсә, барыбер кире килә ул...

> 6

ЙОЛДЫЗЛЫ АЛАЧЫК

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 151–152 (29118–29119) | Сишәмбе | 17 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЯРДӘМ КАРАЛГАН

rais.tatarstan.ru

Ватан хакына

Акчалата түләүләр, хәрби хәрәкәт ветераны статусын алу, психологик ярдәм. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын барыннан да бигрәк әнә шул мәсьәләләр борчый. Аларга ярдәм йөзеннән оешкан «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстандагы бүлегенә соңгы биш айга якын вакыт эчендә генә дә 3,5 меңнән артык кеше мөрәҗәгать иткән. Республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чаралары арту да билгеле булды. Кемгә һәм нәрсә тиеш?

Алдан ук ачыклык кертик: «Ватанны саклаучылар» фондын оештыру турындагы указны быел апрельдә Россия Президенты Владимир Путин имзалады. Ул хәрби хәрәкәтләр зонасын узган ветераннар һәм сугышчыларның гаилә әгъзаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнә. Дәүләт фондының республикадагы бүлеге 1 июньнән бирле эшли.

– Мондый фонд ил тарихында тәүге тапкыр оешты. Бөек Ватан сугышыннан соң да, Әфганстан, Чечня сугышларыннан соң да бу дәрәҗәдәге ярдәм юк иде, – диде «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында фондның республикадагы бүлеге җитәкчесе Гүзәл Удачина. – Казандагы төп үзәктән тыш, Татарстанның 19 шәһәре һәм районында 45 социаль координатор эшли. 1 июньнән бирле безгә 3676 кеше мөрәҗәгать итте. Ярдәм сорап, махсус хәрби операциядә катнашучылар үзләре дә, аларның гаилә әгъзалары да килә.

Гүзәл Удачина сүзләренә караганда, сугышчыларны һәм аларның якыннарын акчалата түләү мәсьәләсе ешрак борчый. «Мәсәлән, яу кырында яралануга бәйле түләүләргә ачыклык кертүне сорап мөрәҗәгать итәләр», – диде ул. Шулай ук, хәрби хәрәкәт ветераны таныклыгын алуга бәйле сораулар да күп. Бу хакта сөйләгәндә, Гүзәл Удачина шәхси хәрби кампанияләрдә катнашучыларның да әлеге төр таныклыкны алырга хокуклары булуын искәртте. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль, психологик ярдәм мәсьәләсе дә көн кадагында тора.

– Фонд эшли башлаганнан бирле, психологик ярдәмгә бәйле 450 мөрәҗәгать кабул иттек. Хәрбиләр үзләре дә, аларның туганнары да килә. Солдат ялга кайткан арада да аңлашылмаучанлык килеп чыккан очраклар бар. Әйе, алар үзгәреп кайта. Моңа өйдәгеләр дә әзер булып торсын иде. Хәрби хәрәкәтләр теләсә кемнең психикасын какшатырга мөмкин, – диде Гүзәл Удачина.

Ахыры 2 нче биттә >

МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯДӘ КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ ГАИЛӘЛӘРЕНӘ ТАТАРСТАНДА КАРАЛГАН ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ

- Татарстанда даими яшәүче, яңа туган балалары булган гаиләләргә, җан башына уртача керем исәпкә алынмыйча, балалар кирәк-ярак комплектларын бүләк итәләр.
- Пенсионерлар, шифаханә-курорт юлламалары белән тәэмин ителгәндә, беренче чираттагы хокуктан файдалана алачак. Шулай ук республиканың өлкән яшьтәгеләре, I һәм II төркем инвалидлары өйдә түләүсез социаль хезмәтләрдән файдалана ала.
- Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларга, шулай ук психик авырулары булган гражданнар өчен, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул ителү өчен өстенлекле хокук бирелә.
- Эшсез дип танылган гаилә әгъзаларының бизнес-планнарын карау экспертлар советы утырышларында өстенлекле тәртиптә алып барыла. Тиешле эш бирелмәгән очракта, гаилә әгъзасы эшкә урнаштыруга ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән көннән башлап 3 көннән дә соңга калмыйча, эшсез дип танылырга мөмкин.
- Республика дәүләт казнасын тәшкил итүче мөлкәтне арендалау өчен түләүләр буенча кичектерү. Түләүләрне кичектереп тору мобилизация срогына һәм өстәмә 90 көн вакытка бирелә. Моннан тыш, хәрби хезмәткәр хастаханәдә яки башка стационарда дәвалана, вакытны озайтырга мөмкин. Кичектерүдән тыш, хәрби хезмәткәрләргә аренданы штраф санкцияләрсез өзәргә мөмкинлек бирелде.
- Участокка газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга 100 мең сумга кадәр субсидия.
- Никахны чираттан тыш теркәү.

БАЛАЛАРГА:

- инвалид балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә, өстенлекле хокукка ия;
- һөнәри белем бирү оешмаларында укучы студентлар – бушлай бер тапкыр кайнар аш, ә 1–11 нче сыйныф укучылары ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин ителә;
- 7 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләр, ялны оештыруга юлламалар белән тәэмин иткәндә, чиратсыз алу хокукына ия;
- 18 яшькә кадәрге балаларга һәм әти-әнинең берсенә (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре үткәргән чараларда бушлай катнашу хокукы бирелә.

Сәламәтлек

Сакланыр чак

ОРВИ йоктыручылар саны кимегән, грипп белән авыручылар юк. Коронавирус йоктыручылар саны да фаразланганнан азрак. Белгечләр республикадагы хәзерге эпидемиологик вазгыятьне әнә шулай бәяли. Әмма саннар чаң сугарлык булмаса да, тынычланырга иртәрәк, ди алар.

Вируслы чирләр баш калкыткан чорда уяулыкны югалтырга ярамый, ди табиблар. Журналистлар белән очрашуда шул хакта искәрттеләр.

Соңгы елларда халыкны дер селкетеп яшәгән коронавирус хәзер бераз йомшара төште. Тормышыбыздан бөтенләйгә үк китеп бетмәсә дә, хәзер ул, нигездә, бернинди билгеләрсез яки ОРВИ рәвешендә генә уза. Рәсми мәгълүматларга караганда, бер атна эчендә Татарстанда 229 кеше коронавирус йоктырган. Бу алдагы атна белән чагыштырганда 65 очракка күбрәк. Ел башыннан бирле республикада ковид белән барлыгы 14050 кеше чирләгән.

Авыручылар саны артса да, хәлләр фаразланганча ук мөшкел түгел, ди белгечләр. Шуңа күрә коронавирус белән авыручылар саны кисәк артып китсә дип әзерләнгән өстәмә ятак урыннарның да кирәге чыкмаган. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов сүзләренә караганда, бу көннәрдә аларны кире сүтәргә җыеналар.

– Вируслы авырулар котырган чорда коронавирус белән авыручылар саны кискен артырга мөмкин, дип фаразлаган идек. Шуны күздә тотып, өстәмә ятак урыннар да булдырдык. Хәзерге вакытта бездә 11 вакытлыча госпиталь эшли. Аларның санын арттырмадык, – ди Лопушов.

– Хәзерге вакытта госпитальләрдә барлыгы 292 кеше дәвалана. Биредәге ятак урыннарның 27,4 проценты буш. Норматив буенча исә аларның 5–10 проценты гына буш булырга тиеш. Шуңа күрә вазгыять ял көннәрендә дә тотрыклы сакланса, коронавирус белән авыручылар өчен исәпләнгән ятак урыннар саны киметеләчәк, – ди Татарстанның баш эпидемиологы.

Бер атна эчендә Татарстанда ОРВИ белән авыручылар саны 15 процентка кимегән. Грипп белән авыруның исә бер генә очрагы да теркәлмәгән. Әмма бу тынычланырга кирәк дигән сүз түгел, ди белгечләр. Вируслы авырулар арта һәм алардан сакланырга кирәк. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина, грипп белән авыручылар саны октябрь ахыры – ноябрь башында артыр, дип фаразлый. Узган ел республикада бу сан 7 ноябрьдә арта башлаган булган.

– Хәзер гриппка каршы прививка ясату өчен иң кулай вакыт. Әлегә бу чирнең бер генә очрагы да теркәлмәде. Шуңа күрә прививка ясаткач, иммунитет барлыкка килергә өлгерәчәк, – ди Любовь Авдонина.

Бу урында кызыклы гына сан да китерде ул. Баксаң, Татарстанда вакцина ярдәмендә соңгы ике дистә ел вакыт эчендә грипп йоктыру очракларын күп тапкыр (!) киметүгә ирешкәннәр икән.

– Күптән түгел генә анализ ясадык. Соңгы 22 ел эчендә гриппка каршы вакцинациягә караш шактый үзгәрде. Элегрәк аны халыкның 10 проценты гына ясаткан булса, хәзер бу күрсәткеч 50–60 процентка җитте. Шушы вакыт эчендә грипп йоктыру очраклары исә 68 тапкыр кимеде, – дип ачыклык кертте Любовь Авдонина.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Виталий МИЛОНОВ, Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты рәисе урынбасары:

Гаиләдә балалар күбрәк булган саен, дәүләт ярдәме дә артырга тиеш. Әйтик, биштән күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә няня яллау өчен ваучер биреп була. Шулай иткәндә, болай да зур чыгымнар күтәргән гаиләләр дәүләт ярдәмен сизәр иде. Ишле гаиләләргә җиде урынлы автомобиль сатып алуга субсидия кертсәк тә артык булмас иде.

(«Парламентская газета»га әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ҖИЛӘК-ҖИМЕШ

«АиФ» белгечләре Россиянең җиләк-җимеш базарына күзәтү ясаган. Баксаң, көндәлек рационда җиләк-җимеш күләменең киңәш ителгән нормасы илнең өч кенә төбәгендә үтәлә икән.

Россиядә яшәүче елына уртача **70,3 кило** җиләк-җимеш ашый. Киңәш ителә торган норма – **100 кило**.

Россия базарында җиләк-җимеш күләме – 8,8 млн тонна (2022 ел күрсәткечләре буенча).

Импорт өлеше – 40%

Әлеге норма
✓Севастополь,
✓Дагыстан,
✓Ямал-Ненец автономияле округында гына үтәлә.

Тырышларга бирәләр

Татарстан электроника җитештерүче технопаркларны үстерүгә федераль үзәктән субсидия алырга тиешле төбәкләр исемлегенә кертелгән. Россия Хөкүмәте матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, безнең республикага 241,8 миллион сум акча биреләчәк. «Электроника эшләп чыгаручы технопаркларга ярдәм итәчәкбез. Якындагы өч елда бу максатка 2,2 миллиард сумнан артыграк акча бүлеп биреләчәк», – дигән Премьер-министр Михаил Мишустин.

Субсидия бирү өчен, төбәкләрне федераль дәрәҗәдә сайлап алганнар. Исемлектә Татарстаннан тыш Владимир өлкәсе (900 миллион сум), Түбән Новгород өлкәсе (632,7 миллион сум) һәм Башкортстан (504 миллион сум) да бар. Аңлашылганча, Татарстан башкаларга караганда азрак акча алачак. Субсидия технопаркларга сәнәгать объектларын проектлау, төзү, яңарту, җиһазлар сатып алу чыгымнарын өлешчә каплауга җибәрелә.

Карашлары – Казанда

Татарстан көзге чорда да туристларның иң яраткан төбәкләреннән берсе булып калган. Fun&Sun туроператоры генераль директоры Владимир Рубцов әйтүенчә, көзге айларда Санкт-Петербург, Казан, Дагыстанга сәфәр кылучылар саны барыннан да күп булган. «Кышын гадәттә тау чаңгысы курортларына ихтыяҗ үсә. Февральдән Байкал тарафларында ял итәргә теләүчеләр ишәя», – дигән ул.

Әйтергә кирәк, Татарстан эчке туризм буенча һәр ел саен алдынгы урыннарның берсен били. Белгечләр фикеренчә, ел әйләнәсе туристлардан өзелмәү – республиканың төп өстенлеге. Авиация, тимер юл транспортының әйбәт йөрүе дә туристлар күңеленә бик хуш килә. Шул ук вакытта Россия Туриндустрия берлеге вице-президенты Дмитрий Горин сүзләренә караганда, Татарстанның чит илләрдән туристлар кабул итү мөмкинлеге дә зур. Әйтик, киләсе елда Кытай туристлары, визасыз сәфәрдән файдаланып, беренче чиратта нәкъ менә Казанга килергә җыена.

Исегезгә төшерәбез: ВЦИОМ үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, быел җәй Татарстан һәм Казан Россиядә ял итүчеләрнең иң яраткан 3 юнәлеше исемлегенә кергән.

Сөембикәле акча

Яңа мең сумлыкның арткы ягында Татарстанның күренекле урыннары пәйда булачак. «РИА Новости» хәбәренә караганда, анда Сөембикә манарасы, Татарстан һәм татар халкының дәүләтчелеге тарихы музее, Уфаның археология һәм этнография музее сурәтләре торачак. Яңа меңлекләр сурәтләренең башлангыч исемлегенә республикадан Сөембикә манарасы, тулаем Казан Кремле, Болгар шәһәрлеге, «Казан» гаилә үзәге кертелгән булган.

Акчаның алгы ягына Россиянең башка күренекле урыннары: Түбән Новгород Кремле, Түбән Новгород ярминкәсе, Чкалов баскычы, «Түбән Новгород» стадионы, Максим Горький һәйкәле, Идел елгасы күренешләре тәкъдим ителгән.

2025 елга кадәр 10, 50, 500 һәм 5 мең сумлыклар да яңартылырга тиеш. Аларның саклау дәрәҗәсен камилләштерү, бизәлешен эшләү күздә тотыла. Узган елда яңа 100 сумлыклар әйләнешкә чыгарылган.

Яңа меңлекләр һәм 5 меңлекләр инде быел ук барлыкка киләчәк. Киләсе елда 500 сумлыкларны яңарту күздә тотыла. Ә инде 2025 елда яңа 10 һәм 50 сумлыклар дөнья күрәчәк.

Карлы яңгыр, көчле җил

Татарстанда рәхәт, җылы һава торышы чигенә. Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, чәршәмбе – 18 октябрьдә көндезге температура +3...+8 градустан артмаячак инде. Төнге сәгатьләрдә +1...+5 градус. Көньяк-көнбатыштан көчле җил, урыны белән карлы яңгыр көтелә. Пәнҗешәмбе – 19 октябрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +5...+10 градус күрсәтәчәк. Төнлә 0...+3.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, җомга һәм шимбә: 20–21 октябрьдә көндез һава температурасы +2...+8 градус чикләрендә тирбәләчәк, төнлә исә 0...+3 градус булачак.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ИҢ КУРКЫНЫЧ ЧАК

Американың иң эре банкларыннан берсе булган JPMorgan идарәсе хәзерге вакытны соңгы унъеллыкларның иң куркыныч чагы дип бәяләде. Хәвефнең төп сәбәбе – геосәясәт: Украинада һәм Якын Көнчыгышта баручы конфликтлар. Болар энергетика һәм азык-төлек базарларына тискәре тәэсир ясарга мөмкин дип исәпләнә. АКШның үсеп баручы дәүләт әҗәте һәм тыныч вакыттагы иң зур бюджет дефициты да киеренкелек чыганаклары буларак искә алына. Бер-берсенә тыгыз бәйләнгән нәрсәләр болар. Әмма без JPMorgan директорларын төзәтергә җөрьәт итәбез: хәвефне геосәясәт тудырмый, геосәясәтне матди проблемалар формалаштыра.

Инде икенче атнага киткән Фәләстыйн фаҗигасенең асыл сәбәпләренә күз төшерик. Аңа этәргечне ХАМАСның көтелмәгән һәм нәтиҗәле һөҗүме бирде, дип аңлаталар. ХАМАС исә: «Без һөҗүм итмәсәк, Израиль һөҗүм итәчәк иде», – дип бара. Тагын бер нәрсәне аңлап китик: Газзәгә һөҗүмне Израиль ел саен оештыра, ел саен йортлар харәбәгә әйләнә. ХАМАС та Израиль өстенә ел саен ракета яңгыры яудыра. Әмма бер елны да АКШның төбәккә шул конфликт сәбәпле очкыч йөртүче кораблар төркеме китергәне юк иде. Инде икенче эскадрилья килеп җитә бит. Америкада һәм Европада моңарчы Фәләстыйнга каршы бу кадәр мәгълүмат сугышы да оештырылганы булмады. Гыйбриләр кулындагы бөтен дөньяның медиа чаралары мәгълүмат кырын шул дәрәҗәдә фейклар белән тутырды: хакыйкатьне тырышсаң да күрү кыенлашты. Мәсәлән, имештер, Катар әмире Көнбатышка газ сатуны туктату белән янаган. Аның видеосы да бар. Гарәп телен белмәүчеләр фейкны ышанып карап утыра инде, әмма видеода сүз бөтенләй башка нәрсәләр турында бара.

Бу юлы сиончылар Газзәне бөтенләй Җир йөзеннән юк итүне максат итеп куйды. Тиңе күрелмәгән вәхшәткә беркем дә комачауламасын өчен, АКШның һәм башка Көнбатыш илләренең гаскәрләре төбәккә китерелде. Англиянең генә дә 24 бомбага тотучы очкычы Иорданиядәге хәрби базада тора.

Сүзне Әнкарадагы Россияне өйрәнү институты белгечләренә бирик әле. Газзә ярыннан көнбатышка таба 30 километрлап киткәч, Gaza Marine дип аталган табигый газ ятмасы бар, диләр алар. Анда 1 триллион куб фунттан күбрәк газ ята. Суешның төп сәбәбе менә шул. Урта диңгезгә килгән американ авианосецы кайда якорь салды дип уйлыйсыз? Төрекләрнең «Габделхәмит Хан» исемле бораулау корабыннан берничә чакрым гына ераклыкта. Төрекләр дә 16 октябрьдән башлап шул төбәктә хәрби-диңгез өйрәнүләре башлап җибәрәләр. Газзә шуннан кул сузымы ераклыкта гына бит инде.

Россиядә

ВАЛЮТА КЕРЕМЕҢНЕ САТ

Сумның девальвациясе Россия җитәкчелеген борчуга салды. Президент Путин долларның кыйммәтләнүе икътисадтагы проблемаларга бәйле түгел, дип күпме генә сөйләсә дә, импорт товарларга бәяләр үсеше тотрыклылыкны аңлатмый бит. Шуңа күрә паровоздан алдан чабучы резерв валюталарын авызлыкларга кирәк дип табылды.

Үзәк банкның ставка күтәрүе көтелгән нәтиҗәне бирмәде. Соңгы ике чараның берсе: экспортчыларга валюта керемнәрен мәҗбүри саттыруны гамәлгә кертеп карарга булдылар. Оппозициядәге финанс белгечләре дә чара күпмедер дәрәҗәдә нәтиҗә бирер, диләр. Ягулык-энергетика, кара һәм төсле металлургия, химия һәм урман сәнәгате, ашлык экспортлаучы 43 компания валюта кеременең 80 процентын илгә кайтарырга, һәм кайткан акчаның 90 процентын сатуга чыгарырга тиеш. Компанияләрнең исемлеге сер итеп саклана, чөнки дус булмаган илләрнең басымы куркыта. Владимир Путин, чара йөз процент нәтиҗә бирәчәк, ди. Доллар элекке 65 сумлык чорга кайтмаячак, әмма үлчәү тәлинкәсе 90 сумнар тирәсендә туктальр дип уйлыйлар. Шуннан да арзанайтсаң, бюджет дефициты якадан алачак.

Сумның тотрыклылыгын хуплаган хәлдә, без карарның «су асты ташлары»н өйрәнеп карарга булдык. Үзәк банк мәгълүматларына караганда, экспортчылар июньдә керемнәренең 82 процентын саткан, хәзер 67 процентка калдырганнар. Илгә мәҗбүри кайтарылган валютаның 90 процентын сатуга чыгару керемнең 72 процентына тигез. Аерма артык зур түгел. Экспортта сумга һәм дус илләрнең валюталарына сәүдә итү көчәйгәнгә, күпме доллар илгә керәсен әйтеп булмый. Белгечләр шулай да чара нәкъ Владимир Путин билгеләгәнчә, ярты ел тирәсе нәтиҗә бирер дип уйлый. Экспортчылар валютаны сатуга чыгарып, үзләре оештырган кече фирмалар аша үзләре үк сатып ала башласа, нәтиҗә булмаска да мөмкин. Валютаны илгә кертү һәм чыгару да – бик катлаулы эш. Монысын да искә алырга кирәк. Президент указы 16 октябрьдән эшли башлады инде, нәтиҗәсе ни рәвешле булуын озакламый күрербез.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru



РӘСМИ ТАТАРСТАН

tatarstan.ru

ОТЫШЛЫ СӘҮДӘ

Татарстанда көзге ярминкәләр дәвам итә. Атнаның һәр шимбәсендә фермерлар, авыл хуҗалыгы оешмалары һәм шәхси хуҗалыклар шәһәр халкына үзләре җитештергән сый-нигъмәтләрен тәкъдим итә. Билгеле булганча, Казанда ярминкәләр 14 мәйданчыкта уза. Узган атнада Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм Татарстанның Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров башкаланың Авиатөзелеш районында оештырылган ярминкәдә булды.

Ленинград урамындагы мәйданчыкта Питрәч, Биектау һәм Буа районнарыннан килгән эре агрофирмалар, кулланучылар кооперативлары, фермерлар ит, балык, сөт, бәрәңге, яшелчәләр, он, җиләк-җимеш һәм куак үсентеләре белән сату итәләр. Биредә 65ләп сәүдә урыны оештырылган. Атна саен 7,3 млн сумнан артык бәягә авыл хуҗалыгы продукциясе сатыла.

Ачык ярминкә мәйданында сәүдә рәтләрен әйләнеп чыгып, Фәрит Мөхәммәтшин сатып алучыларның күплегенә һәм аларның кәефенә игътибар итте. Сатучылар белән кыска вакытлы сөйләшүләрдә ул сәүдә шартлары белән кызыксынды, аларның продукциясен турыдан-туры сату өчен мәйданны киңәйтү буенча теләкләрен тыңлады.

– Иртәнге сәгать җиде генә булуга карамастан, сатып алырга килүчеләр бик күп, – диде ул соңрак журналистлар белән аралашу вакытында. – Бу хәл сәүдәне оештыруның мондый төре кирәклеген күрсәтә. Махсус хуҗалыклар гына түгел, шулай ук фермерлар һәм шәхси хуҗалыклар үстергән продукция бай ассортимент белән отышлы бәядән тәкъдим ителә. Өстәвенә продукция табигый, үзебезнеке. Җитештерүчеләргә дә, кешеләргә дә файдалы.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров фикеренчә, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов инициативасы белән ярминкәләрдә авыл продукциясенә төгәл бәяләр билгеләнгән.

– Үз продукциясен ярминкә мәйданчыкларында сатарга теләгән авыл җитештерүчеләренә транспорт чыгымнары һәм ягулык бәясе субсидияләнә, – дип ассызыклады ул. – Мондый ярминкәләр, авыл халкы үстергән уңышын һәм җитештергән товарын мөмкин кадәр күбрәк сата алсын өчен, декабрь ахырына кадәр дәвам итәчәк. Атна саен без базарның торышын анализлыйбыз, кешеләрнең кәефләрен, сатып алучыларның ихтыяҗын өйрәнәбез, кайсы продукциягә күбрәк игътибар бирергә кирәклеген ачыклыйбыз, төрле мәйданчыкларда товарлар санын һәм ассортиментын көйлибез.

«ЮК!» ДИП ӘЙТӘ БЕЛ

Укытучыларны артык кәгазь эшеннән азат итмәкчеләр. «Мәгариф турында»гы Законга берничә төзәтмә кертелгән. Ул нәрсәдән гыйбарәт? Матбугат очрашуында шулар хакында сөйләделәр.

– Мәгариф системасында кәгазь эшен киметү мәсьәләсе – бик зур һәм күпкырлы проблема. Без моның буенча күптән фикер алышабыз, соңгы ике елда бик актив эшлибез, әмма мондый катлаулы эштә нәтиҗәләр тиз булмый. Моңа шул исәптән белем бирү процессын оештыруда таләпләрнең төгәл булмавы да сәбәпче, – дип сөйләде Рособрнадзор җитәкчесе киңәшчесе, «Мәгариф» дәүләт корпорациясенең үсеш буенча директоры Наталья Алтыникова.

Наталья Алтыникова сүзләренчә, бүген мәгариф системасында кәгазь эшен киметү өчен, федераль нигез булдырылган.

– Бер ел элек без «Мәгариф турында»гы Законга үзгәрешләр керттек, алар бүген үк укытучыларга нагрузканы киметергә мөмкинлек бирә, – дип сөйләде Рособрнадзор җитәкчесе киңәшчесе.

Төзәтмәләр нидән гыйбарәт соң? Беренчесе – Мәгариф министрлыгы укытучылар тутырырга тиешле документлар исемлеген булдыра. Шулардан тыш укытучыдан беркем дә өстәмә документ сорарга тиеш түгел. Икенче төзәтмә исә белем бирү оешмаларына документ әйләнешен, электрон рәвештә алып барылса, кәгазьдә алып бармаска рөхсәт итә. Димәк, укытучылар билгене ике журналга да куеп барырга мәҗбүр ителми.

Наталья Алтыникова сүзләренә караганда, кәгазь, хисап эшләренә зур ревизия үткәреп, артыгын алып ташларга кирәк.

– Барысы да мәгариф системасыннан нидер тели, нидер таләп итә. Бик күп хатлар, мөрәҗәгатьләр килә. «Юк!» дип әйтә белергә кирәк. Әйтик, бүген закон проекты нигезендә сыйныф җитәкчесе тутырырга тиешле биш документ бар. Ләкин чынлыкта без укытучыларның 70 процентының 40–50 төрле документ тутыруны дәвам иттерүен күрәбез. Чөнки мәктәп директорлары, укытучылар, төбәк Мәгариф министрлыклары да «Юк!» дип әйтергә әзер түгел. Хәзер без төбәкләрдә зур эш алып барабыз. Казанда укытучыларның кәгазь эшен киметү буенча чаралар исемлеген тәкъдим итәчәкмен. Алга таба аның буенча барлык төбәкләр дә эшләячәк, – дип сөйләде ул.

Ләйсән САФИНА

ЯРДӘМ КАРАЛГАН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстан районнарында психологлар район үзәк хастаханәләре базасында эшли. Бүген республиканың 23 районында шундый белгечләр бар.

Инде хәбәр иткәнебезчә, ил күләмендә, шулай ук Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына төрле ярдәм чаралары гамәлдә. Россия Социаль фондының Татарстандагы бүлеге идарәчесе урынбасары Елена Полякова кайбер айлык түләүләр турында искә төшерде.

– Сугыш хәрәкәтләре ветеранына ай саен 3896 сум күләмендә акчалата түләү каралган, ә һәлак булган ветеранның гаилә әгъзаларына ай саен 2125 сум күләмендә акча түләнә. Бу ярдәм чарасын алу өчен, хәрби хәрәкәт ветераны таныклыгы кирәк. Хәрби бурычны үтәгәндә һәлак булган яки, сугышта яралану сәбәпле, хәрби хезмәттән азат ителгәннән соң вафат булган хәрбиләрнең балаларына ай саен 2815 сум күләмендә пособие билгеләнә. Моннан тыш, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучының баласына 15548 сум күләмендә айлык пособие гамәлдә. Пособие сабыйга әтисе хәрби хезмәттә булган вакытта, әмма өч яшь тулганчы түләнә, – дип ачыклык кертте ул.

Алга таба Татарстанда ярдәм чараларын тагын да арттырмакчылар.

– Хәрби хәрәкәт ветераннары, хәрби хезмәттән азат ителүчеләргә һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга чираттагы ярдәм чарасы әзерләнә, – диде Гүзәл Удачина. – Сугышчыларга бушлай җир кишәрлеге бирү турында Татарстан Республикасы закон проекты әзер диярлек. Дөрес, яңалык бөтен хәрбиләргә дә кагылмый. Аны депутатлар якын арада узачак сессия утырышларының берсендә үк караячак, дип уйлыйм. Көтәсе күп калмады.

Бүген 10.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр Татарстанда контракт буенча хезмәткә ярдәм йөзеннән патриотик марафон узачак. Белгечләр кызыксындырган барлык сорауларга да туры эфирда җавап бирәчәк. «Ак Барс Арена» стадионында узачак әлеге телемарафонны ТНВ каналыннан күрсәтәчәкләр. Мобилизациягә эләккән ир-егетләрнең гаиләләре, Россия Герое исеменә лаек булган Татарстан егетләре, республика батальоны хәрбиләре көн дәвамында үзләре турында сөйләячәк. Чара узачак мәйданчыкка депутатлар, танылган артистлар, социаль яклау, хәйрия оешмалары, «Ватанны саклаучылар» фонды вәкилләре дә чакырулы – сорауларны аларга да бирергә мөмкин булачак.

КЫЙММӘТЛЕ ЧАКРЫМНАР

Юл хәлләре

Быел Татарстанда юл төзелешенә моңарчы күрелмәгән сумма – 250 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Яңа юллар салу нәтиҗәсендә, мәсәлән, Казан – Мәскәү, Казан – Түбән Кама аралары якынаячак. Татарстанда кайда һәм нинди юллар төзелә?

vtk.rosavtodor.gov.ru

Биш район тоташа

– Агымдагы елда Татарстанда юл эшләренә, зур проектларны тормышка ашыруны да исәпкә алып, 250 миллиард сум акча тотылачак, – дип сөйләде киңәшмәләрнең берсендә Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов. – Чагыштыру өчен: былтыр 209 миллиард сумлык эш башкардык.

Иң зур төзелешләрнең берсе – М12 югары тизлекле трассасы, әлбәттә. Татарстанда әлеге юл республиканың Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Лаеш һәм Питрәч районнары аша уза. Автомобиль магистраленең барлык 142 чакрымы буенча хәрәкәтне быел декабрьдә үк ачарга ниятлиләр. М12 трассасыннан барганда, Казан – Мәскәү арасын узу вакыты 6,5 сәгать тәшкил итәр, дип көтелә.

Иң зур күпер

Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы төзелеше өч этапка бүленгән. Аның беренче өлеше кысасында Чулман аша озынлыгы 1,3 чакрым булачак күпер салалар. Бу – Казан – Екатеринбург югары тизлекле трассасының Татарстанга туры килүче юлында иң зур күпер. Аның бәясе – 23 миллиард сум. Биредә хәрәкәт киләсе ел ахырында ук ачылачак.

– Эш алдан фаразланганнан тизрәк тә бара, – диде, журналистларны Чулман аша салынучы күпердәге эш барышы белән таныштырганда, төзелеш өчен җаваплы «Федераль юл агентлыгының Идел – Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» оешмасы җитәкчесе урынбасары Тимур Хафизов.

Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлының гомуми озынлыгы 81 чакрым тәшкил итәчәк. Ул төзелеп беткәч, әйләнгечтән юл турырак та, тизрәк тә булачак, ди белгечләр. Киләчәктә Казан белән Түбән Кама арасы бер сәгатькә тизрәк үтеләчәк.

«Ил икътисады өчен дә әһәмиятле»

Киләсе елда Татарстанда тагын бер яңа юл ачылачак. Алексеевск – Әлмәт түләүле автомобиль юлы аша нефть каласыннан Казанга ике сәгатьтә барып җитеп булачак, дип көтелә. Хәзер исә бер шәһәрдән икенчесенә кадәр дүрт сәгатьләп барасы. Шәле – Баулы түләүле трассасы кысасында төзелүче Алексеевск – Әлмәт юлы турында сүзебез.

Шәле – Баулы автомобиль юлы М7 һәм М5 федераль трассаларын тоташтырачак. Озынлыгы 145 чакрым тәшкил иткән Алексеевск – Әлмәт юлыннан тыш, аңа Әлмәт белән Баулы арасындагы 100 чакрым чамасы юл һәм Саескан тавыннан Шәлегә кадәр инде гамәлдәге 40 чакрымга якын юл керә.

– Төньяк – көньяк коридорының әһәмияте зур. Яңа юл көнбатыш – көнчыгыш юнәлешендә дә, төньяк – көньяк юнәлешендә дә үсеш мөмкинлеген тәэмин итәчәк. Бу Татарстан гына түгел, ил икътисады өчен дә әһәмиятле юл булачак, – диде әлеге юл төзелеше уңаеннан тармак министры Фәрит Хәнифов.

Казан капкасы

Казанда да төзелеш туктап тормый. Инде икенче ел республика башкаласына көнбатыштан бердәнбер керү юлы булган Горький шоссесын реконструкцияләү дәвам итә. Төзелеш эшләре тәмамлангач, бу юлдан тәүлегенә 11 меңгә кадәр машина уза алачак. Аны һәр якка өчәр полосалы итеп зурайтудан тыш, биредә җир өстеннән – биш, җир астыннан өч җәяүле кичүе, юл чишелешләре төзү дә каралган. Шәһәр халкын велосипед юлы белән дә сөендермәкчеләр. Төзелеш эшләрен киләсе елның октябрендә тәмамларга ниятлиләр.

– Әлеге магистральнең озынлыгы 11,3 чакрым булачак. Юлга светофорлар куелмаячак. Ул башкаладагы иң озын магистральләрнең берсенә әвереләчәк, – диде бу уңайдан Казан мэры Илсур Метшин.

Дәвамлы эш

Бу көннәрдә Казанда Вознесение тракты буенча Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәр хәрәкәт тә ачылды.

– Без Вознесение трактының иң катлаулы өлешендә хәрәкәт ачабыз. Ул федераль үзәкнең зур ярдәме белән төзелде. Проектны тормышка ашыруда теләктәшлек күрсәткәннәре өчен Россия Президенты Владимир Путинга, ил Хөкүмәтенә, Россия Транспорт министрлыгына һәм Росавтодорга зур рәхмәт, – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ачылыш тантанасында. – Әлеге катлаулы юл участогы 13,4 миллиард сум тора! Әлбәттә, аның дәвамы да булачак. Без алга таба да ярдәм сорап мөрәҗәгать итәчәкбез.

Билгеле булганча, Вознесение тракты бөтен республика өчен әһәмиятле проект булып санала. Гвардия урамыннан Җиңү проспектына кадәрге юл аның беренче этабын тәшкил итә. Яңа ачылган юлның озынлыгы – 4 чакрым. Алга таба әлеге юл транспорт хәрәкәтенә бәйле вазгыятьне генә җиңеләйтеп калмыйча, бу тирәдә торак төзелешен арттырырга мөмкинлек бирер дип көтелә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БЕЗДӘН БАШКА ШАУЛАМАС

kzn.ru

САН

Татарстанда агач утырту акцияләре 2011 елдан бирле башкарыла. 12 ел эчендә Татарстанда 8,1 мең гектар мәйданда 32,1 миллион данә агач утыртылган. Чарада 567 мең кеше катнашкан.

Урман хуҗалыгы

Шимбә көнне Татарстанда «Урманны саклыйк» бөтенроссия акциясе узды. Табигатькә ярдәм итәргә теләге булган һәркем бу чарага кушылды.

Агач утырту эшләре «Экология» илкүләм проекты кысасында үткәрелә. 2023 елда Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча ил күләмендә 70 миллион данә агач утырту максаты куелган. Әлеге вакытта 34 миллион данә үсенте утыртылган да инде.

– «Урманны саклыйк» акциясе кысасында бүген Татарстанда 170 урында – 600 гектар мәйданда – 2 миллионнан артык агач утыртылды. Чарада 20 меңнән артык кеше катнашты. Республика урманнарында Европа чыршысы, Себер карагае, вак яфраклы юкә, миләш, имән һәм каеннар тагын да күбрәк үсәчәк хәзер, – ди Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров.

Биектау районының Семиозерка авылы янәшәсендә 8 мең агач утыртылган. Биектау урманчылыгы урманчысы Марс Мусин әнә шулай ди.

– Кумәкләп эшләгән эш күренеп тора. Без үз урманчылыгыбыз тирәсендә 2 гектар җирдә агач утырттык. Өмә өчен урманнардан ерак булмаган, машина белән килергә җайлы булган урыннарны сайладык. Урман эчләрендәге яңарту эшләрен безнең хезмәткәрләр башкара, – ди Марс Мусин. – Көз утырткан агачлар нык була. Аларның 80 проценты үсеп китә. Шунысын да онытмаска кирәк: үсенте дөрес утыртылырга тиеш. Үсентенең тамырларын дөрес урнаштырып, һава калдырмыйча күмеп куярга киңәш итәбез. Яхшы шартлар булганда чыршы 100 елдан артык яши. Шуңа күрә өмәдә катнашучылар, үзләре дә сизмичә, киләчәккә матур эз калдыра.

Агач утыртырга килүчеләр арасында гаиләләр дә бар иде.

– Өмәгә барырбыз дип уйламаган да идек. Дөресен әйткәндә, бу хакта белмәдек тә. Олы улым, мәктәптән кайткач, шимбә көнне бергәләп барыйк әле, диде. Баламның бу уен куәтләп алдык. Сеңлесе Ралинә дә килде. Хәзер менә күңел сөенә: урманда үз агачыбыз үсәчәк, – ди Алсу Салахова.

Казанда яшәүче Хәким Сабиров та өмә турында күршесеннән ишетеп килгән. Хәким абыйга – 72 яшь. Алар хатыны Нәҗибә белән ике ел элек Татарстанга күченгән.

– Гомерем буе агач утырттым. Аларның санын кем белгән... Бу тормышта ирләр башкарасы эшләр үтәлде. Өч улым, ике кызым бар. Ике йорт җиткердек. Нәҗибә апаң белән буш вакытта гел урманда йөрибез. Паркларга чыгабыз. Шуңа да сәламәтлек барында агач утыртырга кирәк, дип уйлыйм. Әле мондый чараларда күп тапкырлар катнашырга исәп, – ди Хәким абый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СЕССИЯ КӨНЕ БИЛГЕЛЕ

Парламентның кырык сигезенче утырышы 19 октябрьдә үткәреләчәк. Дәүләт Советы Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Мәсьәләләрнең бер өлеше каралганнан соң, тәнәфес игълан ителеп, утырыш 2 ноябрьдә дәвам иттереләчәк. Анда киләсе елга республика бюджеты турында закон проекты беренче укылышта кабул ителергә тиеш.

Депутатлар көн тәртибенә кертеләчәк мәсьәләләргә тотынганчы, Фәрит Мөхәммәтшин тәкъдиме белән, 12 нче чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты, 1 нче чакырылыш Дәүләт Советы депутаты Гелий Кобелевның (89 нчы яшендә вафат булган) истәлеген бер минутлык тынлык белән искә алды.

Дәүләт Советы Рәисе соңгы вакытлардагы төп вакыйгаларга күзәтүне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның 2024 елга Дәүләт Советына Юлламасыннан башлады. «Республиканың эчке һәм тышкы хәле анализланган чыгышта төбәк эшчәнлегенең барлык өлкәләренә кагылып үтелде, – диде парламент башлыгы. – Билгеләнгән юнәлешләр буенча эшләү өчен Хөкүмәт белән берлектә Юлламада куелган бурычларны тормышка ашыру чаралары булдырылды».

Фәрит Мөхәммәтшин шулай ук «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумын, 400 кунак катнашында II Казан халыкара юридик форумын, Россия белән Үзбәкстан арасында төбәкара хезмәттәшлек форумын, Татарстан Дәүләт Советы белән Алтай Республикасы Дәүләт Җыены арасында хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелуын һәм башка чараларны искә төшереп үтте.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Мавринаның тәкъдиме белән Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышын 19 октябрьдә үткәрү һәм тәнәфестән соң 2 ноябрьдә дәвам итү турында карар кабул ителде. «2024 елга республика бюджеты турында закон проектын җентекләп тикшерү зарурилыгына бәйле бу, – дип билгеләп үтте ул. – Бу вакытка кадәр комитетларда, парламент тыңлауларында, шулай ук муниципаль берәмлекләрдә бюджет буенча фикер алышулар тәгәлләнергә тиеш».

Лилия Маврина әйтүенчә, парламентның чираттагы утырышы көн тәртибенә 30 мәсьәлә, шул исәптән 17 Татарстан законы проекты кертелә. Шуның 15е – беренче, 2се икенче укылышта каралачак.

Депутатлар 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына республика бюджеты турында, Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектларын карап тикшерәчәк.

Беренче укылышка Татарстанның кайбер законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан закон проектларын, шул исәптән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» һәм башка шундый закон проектларын карап тикшерү дә тәкъдим ителә.

Моннан тыш, Лилия Маврина сүзләренә караганда, Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты «Татарстан Республикасында гражданнарны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү турында» закон проектын кертә. Аны Дәүләт Советына үтмәгән сәяси партияләр вәкилләре катнашында карап тикшерү күздә тотыла.

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы **19 октябрь көнне (10.00 сәгатьтә башлана)** Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә. Депутатлар Дәүләт Советы бинасында **19 октябрьдә 8.00 сәгатьтән** башлап теркәлә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышын 2023 елның 19 октябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 13 октябре, № 2154-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 489-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
2. «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 482-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 484-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 481-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 464-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
6. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 478-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 483-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 458-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
9. «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 480-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 һәм 135^4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 433-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 474-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 477-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 479-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вазыйфага сайлана яисә билгеләп куела торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның таныклыклары турында.
16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
17. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына һәм «Альтернатив граждан хезмәте турында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
18. Хәсәнов Рөстәм Ринат улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
19. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составына үзгәреш кертү турында.
20. «Россия Федерациясе Граждан кодексының дүртенче өлешенә (хокук ияләре билгесез авторлык хокукларының һәм уртак хокукларның аерым объектларыннан файдалану тәртибен билгеләү өлешендә) үзгәрешләр кертү турында» 411043-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
21. «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 441427-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе территориясен чит дәүләтләрдән йогышлы хайван авырулары кертүдән саклау өлешендә).
22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 410399-8 номерлы федераль закон проекты турында (тулы һәм дөрес экологик мәгълүматны яшереп калган, белә торып бозган яисә үз вакытында хәбәр итмәгән өчен административ җаваплылык чараларын көчәйтү хакында).
23. «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2006 елның 21 декабрендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законның 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 396291-8 номерлы федераль закон проекты турында (сертификат алган затның балигъ булган балаларының, шулай ук иренең сатып алына торган торакта өлеш бирелүдән баш тарту мөмкинлеге турында һәм башка торак урын сатып алган очракта аларга өлешләр бирү бурычларын үзгәртү хакында).
24. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333^{33} статьясына үзгәрешләр кертү турында» 441961-8 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт пошлинасы күләмен үзгәртү өлешендә).
25. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93^3 статьясындагы 2 пунктына үзгәрешләр кертү турында» 398197-8 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча һәм муниципаль берәмлек тарафыннан кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча бурыч йөкләмәләрен каплау өчен муниципаль берәмлек бюджетына Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитлары өлешендә).
26. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 485-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
27. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 486-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
28. «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 487-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
29. Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
30. Хөкүмәт сәгате: «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматта күрсәтү турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 13 октябре, № 2155-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы **Гайнетдинов** Ренат Вагыйзь улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Көнчыгыш-Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Миңнегалиев** Насыйх Вазыйхҗан улына, «РемонтСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Назаров** Александр Ивановичка, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Җылылык-энергосервис» муниципаль унитар предприятиесенең суүткәргечләр участогы мастеры **Потапов** Анатолий Геннадьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казан приборлар төзү конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: 22 нче техник контроль идарәсенең агрегатлар, приборлар һәм сизгер элементлар сынаучысы **Абросимов** Владимир Алексеевичка, 22 нче техник контроль идарәсенең агрегатлар, приборлар һәм сизгер элементлар сынаучысы **Билалов** Илдар Мингазиз улына, 34 нче механикаҗыю цехының компаундлар коючысы **Туюрова** Татьяна Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Биккинин** Денис Сергеевичка; «Татнефтепроводстрой» акционер җәмгыяте генераль директоры **Демидов** Иван Петровичка; Казан шәһәренең «Муниципаль торак программалары дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе директоры **Кәримов** Рәис Җиһанша улына; «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Надршин** Айрат Рашат улына; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының сәнәгать төзелеше буенча урынбасары **Нурмиев** Альберт Әнвәр улына; «Алексеевскдорстрой» ачык акционер җәмгыятенең асфальт-бетон салучысы **Бударов** Николай Геннадиевичка; «Татавтодор» акционер җәмгыятенең Арча филиалы йөк төяү машинасы йөртүчесе **Сафиев** Роберт Тәлгать улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

КОБЕЛЕВ ГЕЛИЙ ВАСИЛЬЕВИЧ
(15.06.1935 – 13.10.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Татарстан Югары Советының План һәм бюджет-финанс комиссиясе рәисе, Дәүләт Советының Бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясе элекке рәисе Кобелев Гелий Васильевич 13 октябрьдә 89 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Гелий Васильевич 1935 елның 15 июнендә ТАССР Алабуга шәһәрендә дөньяга килгән. Хезмәт эшчәнлеген Горбунов исемендәге Казан авиация заводында токарь буларак башлап җибәргән. 1961 елда, Казан финанс-икътисад институтын тәмамлаганнан соң, комсомол һәм партия эше вазыйфаларында хезмәт куйган. 1973 елда халык депутатларының Казан шәһәре Мәскәү районы советы башкарма комитеты рәисе итеп сайланган. 1981 елда КПССның Казан шәһәре Мәскәү районы комитеты беренче секретаре вазыйфасына билгеләнә.

Гелий Кобелев Татарстанда дәүләтчелек һәм парламентчылык торгызуга үзеннән зур өлеш кертте. 1985 елдан, XI һәм XII чакырылыш ТАССР Югары Советы составына керәп, ТАССР Югары Советының План һәм бюджет-финанс комиссиясенә җитәкчелек итте. 1995–1999 елларда I Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, Бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе булды.

Алга таба республиканың социаль-икътисадый үсешен финанс ягыннан тәэмин итүгә бәйле төрле вазыйфаларда хезмәт куйды.

Гелий Кобелев республика икътисадына инвестицияләр җәлеп итү системасын булдыруда, шулай ук базар шартларында аның финанс мөстәкыйльлеген көчәйтүдә актив катнашты. Республика һәм җирле бюджетларның керем өлешен нызыйлаштыру буенча бирелдәй законнар актларын кабул итүдә, килешүләргә кул куюда башлап йөрде. «Алабуга» махсус икътисадый зонасын булдыру да аның исеменә бәйле. Ул бүген дә Россиядә иң уңышлы эшләүче махсус икътисадый зоналарның берсе булып тора.

Гелий Васильевичның нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Хезмәт Кызыл байрагы ордены, «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» мактаулы исеме, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, Татарстан Президентының Рәхмәт хаты, Дәүләт Советының «Парламентчылыкны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен» мактау билгесе.

Гелий Кобелев максатка омтылышлы, талантлы оештыручы, игътибарлы остаз булды. Аның эшлекле сыйфатлары һәм кешелеклелеге, эшкә тугрылыгы, югары дәрәҗәдә һөнәри осталыкка ия булуы, кешеләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәте зур абруй-хөрмәт китерде.

Гелий Васильевич Кобелевның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН,
Ә.Ә. СӘФӘРОВ, Р.Р. ГАЙЗАТУЛЛИН, И.Р. МЕТШИН,
Р.М. НУРИЕВ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, XI (1985–1990) һәм XII (1990–1995) чакырылыш ТАССР Югары Советы депутатлы, I чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы (1995–1999)

КОБЕЛЕВ Гелий Васильевичның

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Гелий Васильевичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, элекке XI һәм XII чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты, Татарстан Республикасы халык депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, КПССның Казан шәһәре Мәскәү районы комитеты беренче секретаре

КОБЕЛЕВ Гелий Васильевич

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Гаделлеккә сусау

Бу атнада «Литрес» дип аталган китап сервисы коммунизм һәм социализм турындагы электрон һәм гадәти китапларга ихтыяҗ арту хакында белдерде. Шушы елның гыйнвар – сентябрь айларында, 2022 елның шул чоры белән чагыштырганда, халык андый китапларны 39 процентка күбрәк укый башлаган. Әлеге хәл нәрсәне аңлатырга мөмкин? Халыкның гыйлемгә тартылып, якын тарих белән ныграк кызыксынуынмы? Әллә инде гасыр ярым элек Европа кыйтгасында яралып, узган йөзьеллык башында Россиядә материальләшкән коммунизм шәүләсенең яңадан калкып маташуын, гавамның бер өлешенең шуңа сусаганлыгынмы? Белгечләр күренешне әлегә гади генә аңлата: җәмгыятьтә гаделлеккә, тигезлеккә ихтыяҗ көчәйгән икән бит. Тик…

Тик менә гаделлеккә, тигезлеккә ихтыяҗ XIX гасыр урталарыннан ук көчәя килеп, XX гасыр тууга, аны, гаделлекне, белүебезчә, көчләп урнаштыра да башлаганнар. Без мәктәптә «Европада бер шәүлә йөри – коммунизм шәүләсе» дип башланган Коммунистлар партиясе манифестын өйрәнгән чакларда көчләү инде кимегән, тик гаделлек һаман да урнашмаган иде әле. Шуннан соң ике дистә ел да үтмәде, коммунизм теориясе, тәгълиматыннан да, аның практикасыннан да күмәк баш тарту китте. Бар кешене дә бәхетле итәргә тиешле матур идея үтә каршылыклы, кеше табигатенә туры килми икән бит. Россия өстендә җиде дистә ел буе барган тәҗрибәдән, ул китергән олы тетрәнүләрдән соң, биредә, ниһаять, дөрес нәтиҗәгә килә алдылар.

Шуңа да карамастан, бүгенге яшьләр өчен коммунизм һәм социализм идеяләре, күрәсең, мавыктыргыч. Чөнки алар совет заманында яшәп карамаган. Чорның 50 нче еллар уртасына чаклы дәвам иткән беренче яртысы – террор, ачлык, ялангачлыклар хакында алар гомумән дә мәгълүматсыз. Шулай булмаса, «халыклар атасы» турындагы китаплар белән кызыксыну көчәер, Вячеслав Никонов язган «Ленин. Человек, который изменил все» дип аталган басма үтә популяр булыр идеме икән? «Литрес» китап сервисында коммунизм темасын күтәргән электрон китаплар арасында нәкъ менә Никоновныкы беренче урынга чыккан. Дөресрәге, аудио-варианттагы китап – беренче, текстлысы дүртенче урынны алган. Бер караганда искитмәле инде: халык Ленинның, заманында без мәҗбүри укыган, конспектлаган «Государство и революция», «Империализм – капитализмның югары стадиясе» («Империализм как высшая стадия капитализма») дигән хезмәтләрен, Маркснның «Капитал»ын, ябырылып булмаса да, теләп укый, өйрәнә башлаган.

Моны, чыннан да, халыкның билгеле бер өлешенең капитализмнан, ул китергән гаделсезлекләрдән туюы, тигезлеккә, туганлыкка сусавы дияргә буладыр. Әйе, кешеләрне тигез итеп була. Тик адәми затлар мөмкинлекләре, булдыклылыклары, сәләтләре буенча бер-береннән нык аерылганлыктан, бу эшне, инде әйткәнебезчә, бары мәҗбүриләп кенә башкарып чыгу мөмкин. Тик мәҗбүриләдеңме – ирек бетә, ул юк дигән сүз. Ирек булмагач, тигезлек кирәкме? Ирек яшәмәгәч, гаделлек ярала аламы? Ирексезлек – үзе гаделсезлек бит. Булдыклы, эшчән кешенең ялкаудан яхшырак яшәргә хакы барлыгын исбатлау кирәкми.

Тигез мөмкинлекләр – менә анысы башка. Тигез мөмкинлекләр, тигез старт шартлары – менә кайда чын гаделлек. Капитализмга кеше чырае кергән илләрдә ул бар, эшли. Бәла шунда: Россиядәге капитализм, биредәге мөнәсәбәтләр әлегә тигез мөмкинлекләр тудыра алмады. Биредәге капитал бераз гадел, шәфкатьле булса, җәмгысы утыз ел эчендә без доллар миллиардерлары саны буенча дөньяда икенче урынга чыкмас, ярлылар белән байлар кереме, тормыш сыйфаты арасында упкын ятмас иде. Тигезлекне эзләмәс җиреңнән эзләрсең. Шуңадыр Россия әле бүген дә «сул кәефләр иле» булып кала. Сул кәефләр күзгә төртелеп торган гаделсезлекләрдән, фәкыйрьлектән туа. Явлинский әйтмешли: «Коммунизм ул бетләү кебек – һәрчак хәерчелектә ярала».

Үткән гасырга карасак, без, гаделлек эзләп, тагын да зуррак гаделсезлекләргә юлыктык кебек. Ә менә башкалар, безгә карап, үзләренә яхшы сабак алды, үзгәрде. «Кеше чырайлы капитализм» дигәннән. Бер минутка гына «коммунизм өрәге» тумаган, 1917 елда Октябрь революциясе булмаган, дип күз алдына китерик. Дөньядагы бүгенге капитализм ниндирәк булыр иде икән? Әлбәттә, күпкә саранрак, оятсыз, рәхимсезрәк. Шул исәптән Европада да. Дөнья «швед социализмы» дигән феноменны да, байларга салынган прогрессив салымны да, күп илләр үз иткән киң социаль яклауларны да күрмәс, белмәс иде. Алар белән кешелек Россиягә, анда яралган Октябрь инкыйлабына, Ленинга бурычлы. Инкыйлаб капиталны шөбһәгә салды, үзгәртте. Шунлыктан, Ленинга караш төрлечә булса да, телибезме без аны, юкмы, ул XX гасырның төп кешесе булып кала. Коммунизм тәгълиматының атасы Марксны да кешелек беркайчан онытмаячак. Ләкин даһилар икесе дә, кешелекне яхшыртсалар да, Россиягә дигәндә зыянга булдылар шул…

Әлбәттә, сул идеяләр белән сугарылган китаплар күбрәк укыла башлау биредә яңа инкыйлабка оеткы салына башлауны аңлатмый. Ул күренеш барыннан да бигрәк Россиядәге капитализмның һаман да рәтле-башлы булмавы, биредә «Кем көчле, кем акчалы – шул хаклы» кагыйдәсе белән яшәү күрсәткече. Россияле кавем консерватив-патриотик идеяләрне дә, либераль уй сөрешен дә бүген үз итми. Ул алардан гаделлек көтми. Төп сәбәп шул.

Капитализм, аңа кеше чырае кергән тәкъдирдә, бөтенләй яшәмәслек система түгелдер дә, бәлки. Тик аның кимчелекләре барыбер артык күп. Социализм белән коммунизм исә читтән караганда гына матур, алар барып та чыкмады. «Гаделлеккә ашкынганда, киләчәк ни рәвешле, нинди мөнәсәбәтләргә корылган булырга тиеш соң?» дигән сорау шуңа күрә дә һаман ачык кала.

МАХСУС ХИСЛЕ ОПЕРАЦИЯ

ХӘРБИ БУРЫЧЫН ҮТӘҮЧЕ БАЛТАЧ ЕГЕТЕ НАСЫЙП ЯРЫН ДОНЕЦКИДА ОЧРАТА

Тормышыбыз көтелмәгән борылышлар, сюрпризлар белән туп-тулы. Шөкер, арада сөенечлеләре дә күп. Балтач районының Көшкәтбаш авылы егете Илсаф Нуриев та, Донецк өлкәсенә хәрби бурычын үтәргә баргач, насыйп ярын очратырмын дип уйламагандыр.

Гомерен хәрби хезмәткә багышларга ниятләгән егет бүгенге сынаулы дөньяда әнә шундый көтелмәгән бәхетле «билет»ка ия була.

Кечкенәдән спорт белән дус була Илсаф. Күп төрләре белән шөгыльләнә. Хоккей да уйный, келәмдә дә бил алыша. Ялга кайткан җирдән, үткән ел авыл Сабан туенда бернинди әзерлексез батыр калган.

– Унынчыда укыганда инде ул, хәрби булам дип, үзенә максат куеп, ныклап шөгыльләнә башлады. Үзе сайлагач, каршы килмәдек. Нәселебездә хәрбиләр юк, әмма әтисе Илфат яшь чакта хәрби очучылар әзерли торган училищега укырга кергән булган, ташлап, авылга кайткан. Ә Илсаф мәктәптә укыганда, Коркачыктагы хәрби-спорт аэродромыннан инструктор килеп, Балтачта түгәрәк оештырды, шунда бик яратып йөрде. Башта планерда очарга өйрәнделәр, аннан парашют белән эш итәргә өйрәнеп беткәч, Коркачыкка барып, өч тапкыр парашют белән сикерде. Унберенчене тәмамлагач, Рязаньдагы десантчылар әзерли торган училищега укырга керде. Укырга керүе дә, укуы да бик катлаулы, авыр булды. Әмма ул зарланмады, бик тырышты. Анда да спорт ярышларында актив катнашты, училищеның хоккей командасында капкачы иде, җиңүләре дә күп булды. Укып бетергәч, Казанга кайтып, хәрби автоинспекциягә урнашты. Анда эшләгәндә Мәскәүдә үткән «Армия России» ярышларында, Оренбургта һәм Казанда үткәрелгән, алты ил командалары катнашындагы хәрби һөнәри

Гүзәлия Нуриева

җыеннарда чыгыш ясады. 2022 елда «Танк биатлоны»нда катнашты. Эше командировкалар белән бәйле булса да, якынга кайтты, дип сөенгән идек, – дип истәлекләрне барлый әнисе Гүзәлия.

Махсус хәрби операция башланганда, өлкән прапорщик Илсаф Нуриев Брянск шәһәрендә өч айлык командировкада була. Егеткә яңа бурыч йөкләнә. Быелның гыйнварыннан ул Донецк өлкәсендә хезмәт итә.

Аралашучан Илсаф җирле халык белән дә тиз дуслаша. Алар арасында татарлар да очрый. Шуларның берсе егетне Әминә исемле татар кызы белән таныштыра. Әби-бабайлары чыгышы белән Чүпрәле районыннан булган Әминә – белеме буенча медик. Алгы сызыкта да булырга туры килә аңа. Сәламәтлеген ныгыту өчен, кызны якыннары Казанга кайтарту бәхетенә ирешә. Ә ул, Илсафның Донецкида каласын белгәч, кабат туган ягына кайта… Башта интернет аша гына аралашкан яшьләрнең дуслыгы мәхәббәткә әйләнә.

Октябрь башында инде ялга кайткан яшьләр егетнең туган ягында никах туе үткәрә. Шартын туры китереп, матур итеп үткәрәләр. Санаулы көн тиз үтә. Шушы көннәрдә Нуриевлар тагын хәрби хезмәткә кузгала.

– Туйны Донецкида үткәрергә килештеләр. Илсафның хәрби дуслары, хезмәттәшләре, Әминәнең туганнары шунда бит. «Тукмагың кайда, сукмагың шунда», – дигән әби-бабайлар. Балалары кайда, әти-әни шунда. Туйга без дә барачакбыз, Аллаһы боерса, – ди Гүзәлия.

…Тормыш дәвам итә. Тирә-яктагы борчулы вазгыять тә бәхеткә киртә була алмый. Бәхетләре гомерлек була күрсен.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА



ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

ГАИЛӘ НИГЕЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ун елга – өч йорт! Күптән түгел генә «Ел гаиләсе» бөтенроссия бәйгесендә җиңү яулаган Айгөл һәм Айрат Шәйгардановлар әнә шул кадәрле йорт салып чыкканнар. Осталарсыз, төзүчеләрсез генә. Зур, авыр эшләрне туганнар һәм дуслар белән өмә ясап эшләсәләр, калган барысын да үз куллары белән башкарганнар.

– Мөслимдә беренче йортыбызны өйләнешеп, бер ел узгач, сала башладык. Зур эшләрен бетергәч кенә минем күңел авылга тарта башлады. Әзер йортыбызны тиз генә саттык та авылда әти-әни нигезе янына яңа йорт җиткерергә тотындык. Анысына 2017 елда күчендек. Шуннан бирле авылда яшәдек. Тик балалар үскән саен алар өчен күбрәк мөмкинлекләр тудырасыбыз килде. Үзебез дә көн саен Мөслимгә барып эшлибез. Уйлаштык-киңәштек тә, тәвәккәлләп, менә шушы йортыбызны сала башладык, – дип аңлатты гаилә башлыгы өч йортлы булу тарихын.

Беренче йортларын җиткергәндә – кызлары Айсинә, өч елдан соң уллары Самат туган.

– Без барлык эшләрне дә Айгөл белән бергәләп эшләдек. Нигез күтәрүдән башлап, обой ябыштыруга кадәр. Дөрес, зур эшләрне туганнар, дуслар белән күмәкләшеп башкардык. Йортларның проектын Айгөл эшләде. Бу йортыбызны да үзебезгә уңайлы булсын дип тырыштык. Ниндидер калыпларга ярарга тырышмадык, иң мөһиме үзебезгә ошасын, дидек. Ашыкмыйча, каударланмыйча гына, мөмкинлек булганча, эшләп киләбез, – ди яшьләр.

Айрат – авыл егете. Үзәктән ерак булмаган Метрәй авылында туып-үскән. Айгөл исә – Мөслим кызы. Икесе бер районнан булса да, беренче тапкыр очрашып, танышулары Лениногорск шәһәрендәге музыка-сәнгать училищесында укыган вакытта була. Тик бер уку йортында, бер төркемдә укысалар да, хәтта тулай торакта кара-каршы бүлмәләрдә яшәсәләр дә, ике арадагы мөнәсәбәтләр дуслыктан ерак китми.

– Училищены тәмамлап кайткач, мин – авыл клубында, Айгөл Мөслимдә сәнгать мәктәбендә эшли башлады. Төрле мәдәни чараларда катнашкач, юлларыбыз әледән-әле кисешә иде. Шуннан тагын да якынаеп, очрашып йөри башладык. Бер-беребезне күптәннән белгәч, озакка сузмадык. Ике ай очрашып йөрдек тә, гаилә корырга булдык, – дип елмая Айрат.

Әлеге гаилә тормышта да бик актив. Барысы да җырлый, бии, халык театрында уйный, спорт ярышларыннан да калмыйлар.

– Безнең кичләрен өйдә торганыбыз да юк. Эштән кайткач, Метрәй халык театрына чыгып йөгерәбез. Авылыбызда яшьләр күп һәм алар барысы да бик актив, – ди ут чәчеп торган Айгөл.

Күптән түгел генә әлеге матур гаилә «Ел гаиләсе» бөтенроссия конкурсында җиңүче булды. Җиңү турындагы сөенечле хәбәрне алданрак алган булганнар, ә бүләкләү тантанасы Мәскәүдә 16–18 октябрьдә, ягъни нәкъ менә шушы көннәрдә уза.

– Барысы да «Нечкәбил» республика бәйгесеннән башланды. Анда чыгышлар ясап, супер финалга узып, «Яшь гаилә» номинациясендә җиңгән идек. Шуннан соң безгә Россия бәйгесендә катнашу тәкъдиме килде. Гаиләбез, традицияләр турында видеоязмалар эшләп җибәрдек тә бу турыда оныттык. Шуңа күрә җиңү турындагы сөенечле хәбәр һич көтмәгәндә килеп ирешә. 85 субъекттан 378 гаилә катнашкан. «Яшь гаилә» номинациясендә 87 гаиләне сайлап алганнар, без шулар арасында җиңүче булганбыз, – диде Айгөл.

Йорт нигезен туганнар, якыннар һәм дуслар белән күтәрсәләр, үзләренең гаилә фундаментына хөрмәт, мәхәббәт һәм теләктәшлекне түшәгәннәр Шәйгардановлар.

– Гаиләдә савыт-саба шалтырамыйча тормый, бездә дә төрле чаклар була. Тик ул шалтыраган вакытта берең түзеп, эндәшми калганда, бер-береңә юл куеп, ихтирам итеп яшәгәндә генә матур тормыш корып була. Безнең зәвыклар туры килә. Мин ни уйласам, Айрат шуны әйтеп куя. Ул яктан йорт салганда безгә бик уңайлы булды. Кешеләр ремонт ясаганда да талашып, ачуланышып бетәләр. Ә без өйләнешкәннән бирле йорт салабыз, – дип көлде уңган хуҗабикә.

Әлбәттә, йорт салганда да, гаилә корганда да төп таянычлары әти-әниләре була.

– Аллага шөкер, ике яктан да әти-әниләребез исәнсау. Алар – безнең төп таянычларыбыз, киңәшләре белән дә, хезмәтләре белән дә ярдәм итәләр. Авылдагы йортыбызны да сатмадык. Ял көннәрендә барыбыз да шунда җыйналабыз. Әти-әниләрнең дә бар җирләре төзек, матур, ишле мал тоталар. Шуңа күрә барыбер Метрәй белән Мөслим арасына тузан төшергәнебез юк, – ди яшьләр. – Балаларыбызны да эш белән тәрбияләргә тырышабыз. Татар халкында, оясында ни күрсә, очканында шул булыр, дигән мәкаль бар. Безнең улыбыз да башка балалар урамда уйнаганда, легодан йортлар сала, алар белән төрле бәйгеләрдә катнаша, фантазиягә бик бай. Кызыбыз да безнең кебек үк җырлый, бии.

Алар әйтүенчә, гаилә йорт салганда бары тик үз тырышлыклары, үз мөмкинлекләрен генә файдаланган. Дәүләттән ярдәм тәтемәгән.

– Дөрес, яшьтәшләребез ял итәргә йөргәндә, безнең өчен ял һәм диңгез – шушында. Буш вакыт булуга, гел йорт тирәсендә мәш киләбез, – ди Шәйгардановлар. – Барысын да эшләп карап өйрәндек. Беренче тапкырында «үзебезнеке үзебезгә ярый» дип тәвәккәлләгән идек. Күз курка, кул эшли икән. Кайвакыт кешеләр, безнең стеналарны да штукатурлап бирегез әле, дип сорый. Якын да киләсе килми. Беренче йортыбызны сатмаган булсак, инде әллә кайчан төпләнеп, тыныч кына гомер итәр идек, дип тә уйлаган чаклар була. Әйтергә генә җиңел, ләкин йорт салу – бик чыгымлы, мәшәкатьле эш. Сәламәтлектә дә эзен калдыра. Ләкин шулай да уфтанып, үкенеп, кәефебезне төшереп утырганыбыз юк. Булганына шөкер итеп яшибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҖИР КЕШЕСЕ ҖИРДӘ КАЛА

«Татар-информ»

Милләттәшләр

Мари Эл Республикасының Бәрәңге районы башлыгы Әлфит Ибраев журналистлар белән очрашу вакытында: «Җир кешесе җирдә кала. Мин үземне дә шундыйлар рәтенә кертәм», – дигән иде. Баксаң, аның кебекләр шактый икән бу төбәктә. Авыллар, аның уңган-булган кешеләре белән сокланып та, гаҗәпләнеп тә танышып йөрдек. Үз биләмәләреннән ерак та китмәгән алар, әмма эшләре тау кадәрле. Тәҗрибәләре белән уртаклашырга әзер торалар.

Яңавыл

Гөләфия Мусина белән Инсаф Минһаҗев – ерак туганнар. Әмма сарымсак аларның арасын якынайткан. Бердәнбер көнне шушы файдалы яшелчәне үстереп карарга булганнар. Төрле зурлыкта турап, киптереп, кечкенә пакетларга тутырып, сатарга да әзерләп куйганнар. Исе яман булса да, товары менә дигән.

– Моннан өч ел элек тотынган идек бу эшкә, – ди Инсаф. – Башта Зәйдән 100 кг сарымсак алып кайттык. Анда Марат исемле егет күп еллар шөгыльләнә. Аларның басулары да зур: 19–20 гектар тирәсе. Бер тапкыр шулай биләмәсе белән таныштырып йөрде дә кызыгып киттек. Беренче елны 100 кг сарымсакны кул белән утырттык. Уңыш әйбәт чыкты. Кызык булып китте. Икенче елны Оренбург өлкәсенә барып, 600 кг сарымсак алып кайттык. Бу эшләрнең барысы да үз акчабызга эшләнде инде. Сарымсакны һаман җиргә күмәбез, үрчетмәкче булабыз бит әле. Чыгымы гына бар, кереме юк. Икенче елны бер гектар утырттык. Шуннан эш китте кебек. Дүрт тонна сарымсак җыеп алдык. Эшкәртеп саттык. Эш зурга китә башлагач, агрегатлар алу турында уйлана башладык. Өченче елында, тракторсыз булмас дип, социаль яклау проектыннан файдаланырга булдык. Бизнес-план төзедек. Белмәгәнне өйрәттеләр, булыштылар. Бер кеше дә каршы төшмәде. 350 мең сум акчага трактор алдык. Иске генә булса да, үз эшен эшли. Быел менә дүртенче ел утыртырга җыенабыз сарымсакны.

Иң читене – урнаштыру мәсьәләсе. Шуңа килеп төртелдек. Уйлана башладык һәм җаен таптык. Чистартып, киптереп, он, төрле гранулалар ясап саттык. Башта көнкүрештә кулланыла торган кечкенә генә җайланманы кулланып карадык. Аннан зур киптерү шкафлары алдык. Әлегә кулга зур акча кергәне юк. Әмма төшенкелеккә бирелмибез. Тукай әйтмешли, «эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш...»

Портянур

Рәмис Кәбиров машиналар төзәтү эшенә кайчандыр хобби буларак керешкән.

– Арча көллиятен тәмамлагач, туган авылымда укытучы булып эшләрмен дип уйлаган идем. Үзем дә сизмәстән, машиналар арасында буталып калдым. Кечкенәдән әтием белән техника тирәсендә кайнашканга, күрәсең. Машина төзәтү хәзер төп кәсебемә әйләнде. Күптән түгел үзмәшгульлек программасына кереп, шактый ярдәм алдык. Хакимият башлыгы да гел хәлебезне белеп тора. Бүген дүрт кеше эшләп торабыз. Янәшәмдә – үз авылыбыз егетләре. Яшьләрнең бик өйрәнәсе килә. Үзләренең машиналарын ремонтлап китүчеләр дә бар. Мин болай эшләргә, тегеләй эшләргә кирәк, дип өйрәтеп кенә торам.

Авылдашлары әйтүенчә, башка сервислар кире каккан машиналарны да Рәмис алып кала, төзәтеп бирә икән. Татарстаннан да күп киләләр, ди. «Килгән бер генә кешене дә кире борып чыгарганыбыз юк. Барыбер берәр җаен табабыз», – ди остаханәдә эшләүче егетләр.

Мазарбашы

Фәдбир Хисмәтуллин атлар үрчетә башлаган. Иген игү белән дә шөгыльләнә. Үзе өйдә юк иде. Хәл-әхвәлләрен ярдәмчесе Әсгать Галәветдиновтан сораштык.

– Быел бер гектардан уртача 25 центнер уңыш алдык. Икмәкне урнаштыру – төп проблема. Сатарга урын юк. Бәяләр бик түбән. Сезон вакытында 20ләп кеше эшли. Әмма зарланмыйбыз. «Бизнес биш бармаклы булырга тиеш», – дип юкка гына әйтмиләр бит. Берсе «егыла» башласа, икенчесе шундук ярдәмгә килә. Шуны истә тотып, 2021 елдан бирле ат үрчетү белән дә шөгыльләнәбез. Халыкка ит сатабыз. Кая куйыйк, дип аптырап йөрмәс өчен, колбаса цехы булдырдык. Итне шунда эшкәртәбез.

> Ат үрчетү эшенә яшьләр тартыла. Ат чабышларында да катнашалар. Димәк, яшьләрне авылда калдыру өчен, күңел биреп эшли торган шөгыль булдырырга кирәк.

Андыйлар күп Мазарбашыда. Данис Мөхәммәтҗанов, мәсәлән, тимер эшенә тотынган. Заманында агроном белгечлеге алып чыккан ул. Туган ягына кайткач, җирле үзидарә башлыгы итеп сайлыйлар. Әмма җирлекләрне берләштерү сәбәпле, китәргә туры килә.

– Шуннан Мәскәүгә барып карадым. Юк инде, тегеләй итсәм дә, болай итсәм дә, туган авылга кайтасы килә генә бит. Болай «адашып» йөреп булмас дип, кайттым да тимер эшенә тотындым, – дип искә ала Данис.

48 мең сумлык грант откач, таш эшенә дә керешә ул. Рәсем ясарга һәвәслеге дә бик ярап куя. Авылдагы күп капкалар – аның хезмәт җимеше. Соңгы вакытта чардуганнар, кабер ташлары ясау белән шөгыльләнә.

– Зиратларны яңартырга исәп бар, – ди Данис. – Анда хәзер күп ташларда ни язылганын укып та булмый. Искергән инде. Укып бирүчеләр табылса, акрынлап эшкә тотынырга да мөмкин булыр иде.

Булышучылары да бар аның. Авылда чагында улы белән кулга-кул тотынышып эшли. Кызы исә күбрәк таш эшен якын итә, язу-сызу белән шөгыльләнә.

Авылның тагын бер егете Ришат Әхмәдуллин исә йортларны матур тәрәзә рамнары белән бизи. Аның 15 ел элек бу эшкә тотынуы очраклы гына килеп чыккан кебек. Бервакыт шулай йортын кирпеч белән тышлый ул. Тәрәзә рамнарына заказ бирә. Көтә-көтә арып бетә. Ахыр чиктә дус егете белән икәү ясап карарга булалар. «Болай көтеп ятканчы, үзебез дә булдырабыз дип уйладык», – ди Ришат, ул чакларны искә төшереп. Барып чыга. Аннары дус егетенә ясыйлар. Шуннан китә инде: күршеләр, туганнар заказ бирә. Кеше хакын хаклый торгач, баш-аягы белән шушы һөнәргә кереп китүләрен сизми дә калалар.

– Бар нәрсә дә заказчыларның теләге буенча эшләнә, – ди Ришат. – Бизәкләрен үзләре уйлап табалар яки интернеттан алып тәкъдим итәбез. Бер караганда, милли бизәкләрне пропагандалаган кебек тә килеп чыга инде. Баштарак, татарларга гына кирәк инде бу, дип сөйләнгән марилар түзмәделәр, үз бизәкләрен табып, заказ бирә башладылар.

Егетләр башта гаражда эшлиләр. Сыймый башлагач, йортлары янында гына аерым бина төзиләр. Җәй көннәрендә эшләре бигрәк тә кызу: заказ бирүчеләр дә күп, ялга кайткан студентларның да кирәк-яракка акча эшләп китәселәре килә.

Кыскасы, үз һөнәрчеләре, үз кәсепчеләре бар Бәрәңгенең. Бер дә аптырап тормыйлар. Эшне нидән башларга белмичә тилмереп йөрүчеләргә менә дигән үрнәк бит инде.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Шәфкать

«НАЗ»ДА НАЗ ҖИТӘМЕ?

Балтач

«Монда килгәч, таяк та, яшь тә онытыла». Балтач районының Чепья авылында урнашкан «Наз» тернәкләндерү үзәгенә килүче өлкәннәр шулай ди. Бер тәмен белгәннәр икенче, өченче мәртәбә килергә дә җай таба. «Наз» үзенә нәрсәсе белән тарта ?

Әлеге үзәк бер елга 645 кешене сыендыра. Соңгы вакытта Казан, Түбән Кама шәһәрләре, Саба, Арча, Кукмара, Биектау һәм башка районнардагы өлкәннәр дә «ял йорты»н үз итә башлаган. Кемгә – дәва, буыннарны яздыру, кемгә – аралашу, рәхәтләнеп гәпләшү, матур табигать, җылы мөнәсәбәт. Гомергә өеннән чыкмаган апа-абыйларны да үзенә ияләштерә «Наз».

Арча районының Яңа Кенәр авылыннан килгән Роза Гатауллина – ял итүчеләр арасында иң өлкәне. Киләсе елга аңа 90 яшь тула. Зиһене әйбәт. Әйбәт булмаска, ул бит көн саен хәтерне яхшырту өчен көнегүләр ясый! «Наз»га өченче ел рәттән баруы. «Тагын язылып китәм әле», – ди.

– Украина мәктәбендә балаларга утыз елдан артык немец телен өйрәттем. Аннан туган якка күченеп кайттык. Ирем хәрби иде, өч ел элек вафат булды, – ди әбекәй. – Бер дә картаясы килми. Монысы үзебездән дә тора. Иртән торгач, башта татарча, аннан немец, рус, украин телләрендә исәнләшәм, үз исемемне, туган елымны әйтәм. Немец телен онытмаска тырышам. Ризык пешергәндә яки башка берәр эшне башкарганда, шул хакта алманча үз-үземә сөйләп карыйм. Барысы да искә төшә. Хәтер мүкләнмәсен өчен кирәк бу, кызым. Ә менә яңа сүзләрне истә калдыру авыррак.

Арада ирле-хатынлылар да күренгәли. Гомер буе бер-берсенең кадерен белеп яшәгән парлар аерым йөрергә яратмый. Куныр авылыннан килгән Җиһания апа белән Камал абый да шундыйлардан. Гаилә башлыгы – колхозда шофер, ә Җиһания апа авыл советында секретарь булып эшләгән.

– Җай чыкканда, ел саен килергә тырышабыз. Бер дә, ике дә булгалый. Вакыт кына җитми. Өйдә оныклар бар бит. Улыбыз, киленебез белән яшибез. Кайтуыбызны сагынып көтеп торалар. Үзебез дә шулай, – ди Җиһания апа. Сүзгә 78 яшьлек Камал абый

кушылып: «Карчыгымның миннән башка бер җиргә барасы килми», – дип елмая.

Кукмараның Күкшел авылында яшәүче Галия апа Гарипова да ошаткан «Наз»ны. Юкка гына бишенче тапкыр килми. Фермада 40 ел сыер сауган ул. Эшләгән вакытта ял итәргә, шифаханәләргә йөрергә җае чыкмаган.

– Бигрәк тә мөнәсәбәт ошый безгә. Шәфкать туташлары да, башкалар да елмаеп кына тора. Сәламәтлегем әйбәт үзе. Аралашу – җанга үзе бер дәва. Үзебезгә шөгылен дә табабыз. Дәвасы да килешә. Кукмарадан дүрт кеше килдек. Бергә ял итү өчен алдан язылып китәбез, – ди Галия апа.

Социаль мәсьәләләр буенча белгеч Фидәлия Мостафина әйтүенчә, әби-бабайларны дәвалау төрләре кызыксындыра. Магнит, кул массажына кызыгалар. Йөрмәс аякларына шифа табалар. Ремонттан соң тоз бүлмәсе эшли башлаган. Физкабинетлары төрле аппаратлар белән җиһазландырылган.

Өлкәннәр боекмасын өчен, чараларның төрлесен оештыралар. Бабайлар сирәк күренә. Физкультура ясауны да ялга саныйлар монда. «Өйдә ясарга вакыт тапмыйбыз. Ә монда бергә-бергә күңелле, буыннар да языла. Иске машинаны гел карап торырга кирәк. Без дә шуның кебек инде», – ди Галия апа.

Музыкаль кичәләрне дә бик яраталар икән. Районның авыл клублары хезмәткәрләре җыр-моң белән күңелләрен күтәреп киткәли. Кайберләре Балтач буенча экскурсияне оештыруны да сорады. Читтән килүчеләрнең барысын да күрәсе килә. Элек музейларга йөрткәннәр, хәзер автобус юк икән. Тик шулай да теләкләрен үтәргә сүз бирделәр.

– Өлкәннәрнең – үз холкы, көйсезлеге. Сезне «биетә»ләрме? – дип тә сорадык.

– Арада төрлесе була. Бик «боевой»лары, таләпчәннәре дә очрый. Кайберләре ике кешелек бүлмә, бүлмәләрдә душ, бәдрәфләр булдыруны сорый. Бу – элеккеге хастаханә бинасы бит, үзебез ремонт ясап торабыз. Капиталь төзекләндерү кирәк, – ди Фидәлия Мостафина.

Ял бәясе пенсия күләменнән чыгып билгеләнә. Күп дигәндә 2–3 мең сумга рәхәтләнеп ял итәргә була икән. Түләүле сеансларның хакы – 60–70әр сум. Чит районнардан килергә теләүчеләргә Социаль яклау бүлекләрендә электрон чиратка язылырга кирәк.

Сәрия МИФТАХОВА

Авыл җаны

Акъяр өмете

Миләүшә апа Халикова – районыбызның җирле шагыйрәләренең берсе. «Аулак өй батл»да да көч сынашты. Узган ел Чаллыда шул уңайдан «Күңел» радиосында чыгыш ясарга килгәч тә очрашкан идек. Районадагы әдәби чараларны да еш кына үзенең «табадан гына төшкән», «әле генә язылган», «юлда килгәндә язып куелган» шигырьләре белән төрләндереп җибәрә. Кыскасы, шигъри күңелле, бөтен кешегә дә игътибарлы, ачык, шөкрана кылып яшәүче кешеләрнең берсе ул.

Шәһәрдә баш бухгалтер булып эшләгән вакытта, булачак каенана-каенатасы олы яшьтә дип, кырык ел элек авылга кайткан ул. «Эшемнән фатир ачкычлары да бирәселәр иде», – ди. Ләкин авылга кайтканына үкенми. Хәтта берара кызыл дипломлы белгечкә колхозда төрле кара эшләрдә эшләргә туры килсә дә. Әйткәнемчә, кыенлыкларны күзенә туры карап каршы алучылар рәтеннән Миләүшә апа. Исәнлеге булган кешегә авылның уңай яклары бик күп: иркен итеп, бар уңайлыгы булган йорт җиткереп, бакча үстереп, терлек асрап, зур мегаполислардагы шау-шу арасында яшәгәнгә караганда матуррак яшәп була, дип саный ул.

Ул яшәгән Акъяр – олы юлдагы татар авылы. Заманында, бөтен җирдәгечә, зур мәктәбе, клуб, ферма кебек барлык атрибутлары булган авыл. Хәзер дүрт сыйныфка – сигез бала. Балалар бакчасында унсигез икән! Бу инде – зур сан.

«Бүгенге авылда, кызганычка, үз вакытында тырышып-тырмашып әйбәт тормыш корган пенсионерлар күбрәк. Авылда төпләнеп калган, авыл хезмәтен сөйгән яшьләребез дә бар анысы. Алар җир алып эшкәртеп, гаиләләре белән шәхси хуҗалыкларын булдырып, эштән курыкмыйча, азык-төлекне күп итеп җитештереп, сокланырлык итеп яшиләр!» Күбрәк якын-тирәгә йөреп эшлиләр икән яшьләр: Чистайга, Яңа Чишмәгә, Каргалыга... Авылга килеп эшләүчеләр дә бар. Тракторчылар, фермада эшләүчеләр. «Хәзер ферманы ташып бетергәч, үзебезнекеләргә дә эш калмый инде, нишләп бетәрләр», – дип көрсенә ул.

«Авылларны саклап калу мөмкинме?» – дип сорыйм аңардан да. Ул: «Бары әйбәт эш урыннары, торак корып, күпмедер уйлап эшләгәндә генә авыл тормышын киләчәктә яңадан тергезеп булырга мөмкиндер, – ди. – Моңа илебезнең шул юнәлештә гомуми зур гына программалар эшләп, аның нәтиҗәсен тәэмин итеп торуы кирәктер. Илебездә авылга булышуның төрле ысулларын файдаланып, яшьләргә дә, олыларга да хөкүмәтнең уңай карашы кирәк».

«Сөт-ит бәяләре шырпы, ягулык, коммуналь хезмәт бәяләреннән бик тә калыша, алар «тормозда». Менә шул борчый. Шатландырганы: авылда асфальт юллар, һәр йортта газы, суы, бар кирәгеңнең дә булуы».

«Буш вакыт?! Минем сәламәтлек начаррак, шуңа вакытымны эштә бик аз уздырам. Ун ел пенсиядә. Газета-журналлар укыйм, интернетта «утырам», кроссвордлар, ребуслар, судоку чишәм, ашарга тәмле итеп пешерергә яратам. Китап укыйм, шигырьләр язам».

«Хыялым – озын гомерле булып, исәнлектә балалар, оныклар бәхетен күреп, авылда яшәүнең тәмен табып яшәү генә. Авылыбызда, дөньябызда тынычлык кына булсын иде, Бер Раббыбыз».

Стакан яртылаш бушмы, әллә яртылаш тулымы? Оптимист-пессимистларны билгеләүче бу сорауны бирсәк, Миләүшә апа, әлбәттә, «тулы!» дияр иде. Нинди генә вазгыятьтә дә, нинди генә шартларда да тормыштан ямь табып яши белүчеләр була. Хәер, тышкы тирәлек кешенең бәхетле булуына бары ун процент кына тәэсир итә, ди бит белгечләр.

Лилия ФӘТТАХОВА

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

Тарих, яки Песи баласы

Тел, милләт дип борчылу тойгысы бар. Һәркемдә дә бардыр инде ул. Баш миендәге сырларын заман җилләре тигезләп бетермәгән булса, андый тойгы яшәргә тиеш. Кемнеңдер теленә чыга ул, кемнеңдер эш-гамәлләрендә чагыла, ә кемнеңдер күңелендә генә саклана. Иң яшерен җирендә. Әйтелмәгән мәхәббәт шикеллерәк...

Шартлы рәвештә әйтү инде бу. Халкың язмышы, аның кыйммәтләре өчен борчылу тойгысы төрлечә чагылырга мөмкин. Музейдагы кылыч шикелле мәгърур һәм файдасыз булырга да, аяк астындагы песи баласы сыман атларга ирек бирмичә сырпаланып йөрергә дә, идәнгә төшкән ипи сыныгы кебек үз вакытын көтеп ятарга да мөмкин. Ләкин ул бар. Чөнки адәм баласы – аерым берәмлек кенә түгел, ә төркемгә бәйле зат та.

Үзбилгеләнешен ул үз шәхесенә бәйләп кенә кабул итми. Әйе, ул – кеше... Эт тә, песи дә түгел, ә кеше. Кешенең ир-егет яки хатын-кыз дигән өлешенә карый. Ир-егетнең, әйтик, малай дигән төркеменә керә. Әлегә абый да, бабай да түгел. Шундый-шундый илдә яши торган кеше, димәк, шул илнең гражданы. Шундый-шундый республикада яши. Шундый-шундый телдә сөйләшә, димәк, шул милләт вәкиле. Әти-әнисенең матди мөмкинлекләренә карап, ул үзенең нинди катлауга керүен дә чамалый. Шул рәвешле, үз урынын билгеләгәч, бу урынның әйбәт якларын эзләргә керешә.

Кешенең табигате шулай: ул үзен әйбәтрәк итеп күрсәтергә тырыша. Әлегә берниндә дә яхшылык кылып өлгермәгән булса, нәселе, данлыклы ата-бабалары белән мактана. Аларның бик мактанырлык җире булмаса – уйлап чыгара, хурланырлык булса – бу гамәлләренә аклану эзли, гаеп-кыекларын төзәтергә тырыша. Менә без кечкенә чагыбызда: «Минем әти барысыннан да көчле!», «Минем әни барысыннан да чибәр!» – дип әйтәбез. Барыбыз да шулай, чөнки без – табигатьнең әнә шундый төренә карый торган затлар. Һәм бу әти-әниләребез шундый батыр да, матур да булган өчен түгел, ә үзебезне әнә шул көчле дә, чибәр дә кавемнең бер өлеше итеп тоярга теләгән өчен. Табигый эгоизмның бер чагылышы. Яхшылык эшләргә инде соңга калса, әйтик, ул картайган булса, үзенең һәм иңдәшләренең кылган гамәлләрен матурлабрак күрсәтергә тырыша. Теләсә кайсы кешенең мемуарларын укыгыз...

Мемуарларында кеше үзенең үткәннәрен акларга, матур итеп күрсәтергә, данларга омтыла. Хәтта явызлыгы белән даны чыкканнар да. Моның өчен ул хәтта башкаларны пычратудан да тайчанмый. Халык әнә шундый кешеләрдән тора.

Халыкның яки дәүләтнең үзе язган тарихы да әнә шул мемуарлар шикеллерәк: ул үзенең уңышларын күпертебрәк күрсәтә, гөнаһларына аклау таба, кайбер нәрсәләрне төшереп калдыра яки инкарь итә. Әле шул мемуар яки тарих язылган чактагы вазгыятьнең тәэсире дә зур була. Шуңа күрә, кемнең нәрсә турында язуы гына түгел, ә кайчан язуы да мөһим. Тагын бик күп вактөякләр мөһим. Менә шул рәвешле тарих буталып бетә.

Ләкин без кем мемуарларын укыйбыз, шуңа ышанабыз. Кем язган тарихны укыйбыз – шул дөрес дип уйлыйбыз. «Бәлки, чынлап та шулай булгандыр? Кем белсен? Без бит ул дәвердә яшәмәгән. Әле монда үзең яшәгән заманны да аңлап бетереп булмый...» Шулай уйлыйбыз да... Без тарихтан дөреслек эзләмибез, без тарихтан үз дәрәҗәбезне күтәрә алырлык дәлилләр эзлибез. Һәм бу гаеп тә, гөнаһ та түгел, ә кеше психологиясенең бер үзенчәлеге.

Акыллы сәясәтчеләр моны оста куллана. Көндәшләренең тарихын я гариплэп күрсәтергә, я бөтенләй юкка чыгарырга тырышалар... Халыкларга тарих аша тәэсир итү, тарих аша басым ясау күренеше белән очрашканыгыз бардыр инде? Күрсәгез, танымый үтеп китмәгез, дип әйтүем...

Без еш кына «Нигә балаларыбыз чит телләрдә сөйләшергә тырыша икән? Ник башка милләткә тартылалар икән?» ише сораулар белән баш ватабыз. Бу – үзбилгеләнеш канунының бер чагылышы: аларның зуррак, көчлерәк, матуррак төркем вәкиле буласылары килә.

Аңлаешлырак булсын өчен, моны кечерәк даирәгә күчереп карарга мөмкин. Бер үсмер дә әти-әнисенең алкаш яки наркоман булуын теләми. Әтисе берне әйтеп, әнисе икенчене сөйләп, юктан да гауга чыгарып, көн дә җәнҗал куптарып яшәгән гаилә дә балага бәхет китерми. Ата-анасының читтә азгынлык кылып йөрүен белү дә фаҗигагә әйләнә. Андый ук чиккә барып җитмәгән хәлдә, ялкау, булдыксыз, гамьсез ата-ана да бала күңеленә яра сала. Үз балаларын яратмый, кадерләми, аларның уңышы өчен сөенә белми торганнары да шулай. Тагы әллә күпме санарга мөмкин. Әти-әни йортын ташлап качучы балалар, нигездә, әнә шундый ояларыннан котылу юлы эзләп китә. Тыныч, тату, хәстәрлекле гаиләдән, үзләрен яратып һәм кадерләп торган җирдән китүчеләр юк. Булган очракта да, болар – чит-ятларның нинди дер йогынтысына бирелүче сирәкләр генә. Сабыйларның бәхетле һәм уңышлы гаилә әгъзасы, яхшы ата-ана баласы буласы килә. Һич югында шулай күренәселәре килә.

Әгәр кеше нинди дә булса басымга дучар ителә яки үзен монда кадерсез, кирәксез, ятим итеп тоя икән, ул гаиләсен дә, дәүләтен дә, милләтен дә ташлап китәргә мөмкин. Ул үзен зур итеп һәм затлы кавем вәкиле итеп тоярга тели. Һәркемнең гомере бер генә һәм аның турырак юлны эзләүгә табигый хокукы бар.

Бүгенгене матурлау эшен тарихны матурлаудан башларга кирәк. Халыкны тергезү өчен, тарихын тергезү мөһим. Һәм ул тарих музейдагы кылыч кебек ятмасын, анда хәзер кеше сирәк бара. Ул аяк астындагы песи баласы кебек уралып йөрсен. Теләгәндә тотып карарлык, башыннан сыйпарлык, артык йөдәтсә, тибеп очырырлык булсын. Песи баласы, бер үз итсә, барыбер кире килә ул...

ТЕЛ КҮРСӘТҮ

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ «ТАТАРЧА ДИКТАНТ» ЯЗДЫ

«Өтер белән ноктаны кайчан кайда куйганны» елга бер мәртәбә булса да искә төшерә ул. Дөнья күләмендә уздырыла торган «Татарча диктант» турында сүзебез. Кулга каләм тотмаска ияләнгән бармакларны эшкә җигеп, я булмаса компьютер каршына утырып, татарлар ел саен диктант яза.

Быел да искәрмә булмады. 13, 14, 15 октябрь көннәренә билгеләнгән акциядә без дә катнаштык. Диктантны КФУның Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында яздык.

Ихтыярый чара булса да, яшерен-батырын түгел, акциягә уку яки эш урыныннан җибәрелгән кешеләр дә шактый килә. Кызганыч, быел Казандагы төп мәйданчык аларны исәпкә алып та тулмаган иде. Хәтерлим: берничә ел элек алма төшәрлек кенә урыны була иде ул залның. Әллә кеше килеп язарга иренә, әллә теләк шулкадәр генә калды, әллә башкасы шунда. Ничек кенә булса да, ничәләп кеше катнашканын хәбәр итәрләр әле.

Быел «Татарча диктант» сигезенче тапкыр узды. Диктантны офлайн мәйданчыкларда – кулдан, онлайнда клавиатура ярдәмендә язарга мөмкин иде. Икенче юлны сайлаган очракта, нәтиҗәләрне көнендә үк белергә мөмкин. Ә офлайн мәйданчыкларда язылган диктантның нәтиҗәләрен 15 ноябрьдән соң diktant.tatar сайтына кереп карарбыз.

Быелгы акция замандаш язучыларыбызның әсәрләренә мөрәҗәгать итү белән үзенчәлекле иде. Татарстанлылар – Рөстәм Галиуллинның «Васыять» романыннан, Россия төбәкләрендә яшәүчеләр – Марсель Галиевның «Тимә, яшәсен!» новелласыннан, чит илләрдән катнашучылар Фоат Садриевның «Таң җиле» романыннан өзек язды.

Аңлаганыгызча, «ВТ» хәбәрчесе «Васыять» романыннан өзек язды. Безгә аны профессор Гөлшат Галиуллина укыды. Тарихи роман сайланса да, өзек катлаулы түгел иде үзе. Китап укыган, диалогларның нәрсә икәнен белгән кеше яза алырлык текст. Аның авторы Рөстәм Галиуллин үзе ничегрәк язган соң? Авыр булганмы?

– «Васыять» романыннан өзек алынасын белгәч, бик сөендем. Ләкин нәкъ менә бу өлеше алыныр дип уйламаган идем. Шуңа күрә беренче укыгандай, чит кеше әсәрен ишеткәндәй булдым. Гомумән алганда, бу текстны алуларына, авторы буларак кына түгел, Таҗетдин Ялчыгол шәхесенә игътибар күрсәтүләре өчен сөендем. Быел аның тууына 260 ел тула. Үз чорының күренекле әдибе, милли юлбашчысы, дин галиме һәм күренекле имам була Таҗетдин Ялчыгол. Менә шундый шәхескә игътибар бирүләре бик куандыра. Әлеге чара дәвамлы булса иде. Халкыбызны уятып җибәрүдә, берләштерүдә, туган телебезне пропагандалауда бик зур әһәмияткә ия. Үзем дә «Татарча диктант»ны ел саен язарга тырышам, – диде ул.

Инде өтер-ноктаалар, хәреф хаталарын барлаганнан соң, аягүрә басып һәм Сәйдә Мөхәммәтҗановага кушылып, «Туган тел»не җырладык. Сәйдә үзе «Татарча диктант»ны ел да калдырмаска тырыша икән.

– Быелгы текст миңа бик ошады. Иң мөһиме – ул мәгънәле, күпмедер бүгенге көн белән дә аваздаш иде. Аны катлаулы димәс идем. Авырлык тудырган сүзләрне экранга чыгардылар, – диде ул. – Мондый чаралар, иң беренче чиратта, телебезне онытмас өчен кирәк. Ярый, көндәлек тормышта аз-маз сөйләшәбез, ди. Ләкин туган телебездә сирәк язабыз бит. Татар телен камилләштерер өчен менә дигән форсат бу.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Татарча диктант» – саннарда

2022 елда диктантны барлыгы 1106827 кеше язган. Акция 31 илдә һәм Россиянең 74 төбәгендә узган. 2021 елда катнашучылар саны – 1023738, 2020 елда – 378875, 2019 елда 85000 булган.

Сораштыру

Миләүшә ГАЙФУЛЛИНА, Бөтенроссия «Татар гаиләсе» фонды җитәкчесе:
– Минемчә, бу акциядә үзен татар итеп хис иткән, милләте белән горурланган һәр кеше катнашырга тиеш. Татарлар элек-электән мәгърифәтле халык булган. Бүген менә шундый акцияләр ярдәмендә без моны кабат раслый алабыз. Без күпмилләтле Татарстанда башка халыкларны хөрмәт итеп яшибез. Телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу өчен дә бергәләп тырышыйк.

Булат ИБРАҺИМ, шагыйрь:
– «Татарча диктант»ны икенче мәртәбә язам. Мәктәптә диктантларны күбесенчә «5ле»гә яза идем, «4ле»се дә булгалады шунда. Мондый чаралар, беренче чиратта, дөньяда татар теленең барлыгын күрсәтү өчен кирәк. Телебез – дөньякүләм аренада яши торган тел. Аның киләчәге булсын өчен, мондый акцияләр даими оештырылырга тиеш.

Рәфис АТАКАЗ, татар блогеры:
– Бу акция турында күптән беләм. Ләкин, оятыма, беренче мәртәбә катнашам. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы булсам да, китаплар күп укысам да, татар телендә сөйләшсәм дә борчылам. Мәктәптә рус теленнән дә, татар теленнән дә диктантларны яхшы билгеләргә генә яза идем. Мондый чаралар елына бер генә түгел, берничә мәртәбә узсын иде ул.

МОҢ ИСӘН ӘЛЕ!

Чаллы театры матбугат хезмәте

Премьера

Театр тарихында үз урынын тапкан, еллар, гасырлар дәвамында актуальлеген югалтмаган җәүһәрләр бар. Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» драмасы – шундыйлардан.

Туры мәгънәдә татар хатын-кызларының баш киеме булган ак калфак – аклык-сафлык һәм намус символы. Спектакль аның аша хисләрнең яктылыгы һәм караңгылыгы, горурлык һәм тәкәбберлек, мәхәббәт һәм нәфрәт турында сөйли.

«Ак калфак» драмасы 1922 елда автор тарафыннан башта «Хәмдия» дигән исем белән языла. Бу хакта Мирхәйдәр Фәйзи көндәлегендә: «Бер бүлекле «Хәмдия» дигән пьесамны төгәлләдем», – дип белдерә. Пьеса ел дәвамында тулыландырыла, үзгәрешләр кичерә. 1923 елның 25 гыйнварында Нури Сакаев драманы Уфа сәхнәсендә куя, тик спектакль авторга ошамый: «Начар уйнадылар, киемнәр дә ошамады. Актрисадагы калфак кына ошады», – дип яза ул. Шуннан соң әсәргә тагын төзәтмәләр кертә һәм исемен «Ак калфак» дип үзгәртә. Димәк, «Ак калфак»ка – 100 яшь.

Чаллы театрының сәнгать җитәкчесе, режиссер Олег Кинҗәгуловны пьеса бүген кай ягы белән җәлеп иткән?

– Бер гасыр узса да, пьесада күтәрелгән темалар шул ук бит. Совет заманында бар кеше дә тигез дип килсәләр дә, ул чакта социаль тигезлек булганмы? Бүген олигархларны һәм ярлыларны карагыз... Көтүче һәм морза кызы арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдырган гади бер мелодрама түгел бу, катлаулы, күпкырлы классик әсәр. Нинди генә персонажга, кайсы гына темага тотынсаң да, бик кискен, актуаль сорауларга килеп чыгасың. Әйтик, Хәмдия үзе турында: «Мин – мәзлумнарны яклаучы кыз», – дисә дә, ул – үз алдында конкрет максат күргән, шөһрәткә омтылу юлында үзе өчен матур әкият тудырган («исемемә атап көй чыгаручы минем ярым булачак!»), мин-минлеге көчле персонаж. Үзе турында өченче заттан сөйләвенә генә игътибар итегез!.. «Ирек сөям», – дигән Бакый да, бер мизгелдә күзләре кинәт «сукыраеп», кискен үзгәреш кичерә. Баш очында балта эленеп торганын бик яхшы аңлаган хәлдә, бай кызына мәхәббәт аңлатырга җөрьәт итә...

Спектакльдә Бакый ролен Руслан Әюпов башкара. Актерның сәхнә сөйкемлелеге, вокал мөмкинлеге драманың халыкчанлыгын, үлемсез җырларын һәр тамашачыга бөтен барлыгы белән җиткерә. Аның персонажы – гади көтүче булып кына калмыйча, морза улы Шаһтимер (Фердинант Насретдинов) авызыннан яңгыраган «Син – бер асыл зат, ахры» дигән сүзләргә ияреп, үзенә читтән караган, каршылыклардан торган ир-егет. Пьесадагы вакыйгалар 1860 елда бара. Автор бу датаны махсус ассызыклап күрсәтә, чөнки бер ел үткәч, 1861 елда император Александр II крепостное правоны бетерү турында манифестка кул куйган... Байларга, морзаларга бил бөгүче татар крестьяннары арасында да каршылыклар көчәйгән чор бу. Кешеләрнең авыр тормыштан, кыерсытудан тәмам туйган, үз язмышлары турында уйлана башлаган чагы. Бакый кебек ир-егетләрдән салкын акыл, нык беләк, кайнар йөрәк таләп ителгән вакыт.

Пьесаның совет чорында, кызыл террор елларында язылуына игътибар итсәк, авторның морзаны һәм аның гаиләсен ни сәбәпле тискәре яктан күрсәтүе һәркемгә аңлашылыр. Сәхнәдә Сәлим морза (Татарстанның халык артисты Рафик Каюмов) Мирхәйдәр Фәйзичә калса да, яңа табышлар ярдәмендә тамашачы аның күңеле нечкәргән мәлләрен дә күрергә өлгерә; ирен һәрдаим котыртып, ничек идарә итәргә кирәклеген өйрәтеп торган хатыны Җиһан (Татарстанның атказанган артисты Алсу Хәбетдинова) йөзендә матриархатның көчен дә тагын бер кат үзе аша үткәрә.

Чаллы театрында куелган спектакль кай ягы белән үзенчәлекле? Бу сорауга режиссерның төп җавабы: «Хәмдия турындагы стереотипларны җимердем».

Чыннан да, яшь артист Физәлия Габидуллина уенында Хәмдия һич кенә дә самими, хыялый бер кыз бала түгел. Автор теләгәнчә, әйе, аның бәхетле буласы килә, тик ул үзенә катлаулы каршылыклар уйлап чыгара. Тамашачы алдына ул башкаларның хис-тойгылары белән идарә итүче усал әти янында үсеп, үзе дә каты бәгырьлегә әйләнгән; әкияти, шул ук вакытта үзе өчен дә, башкалар өчен дә хөкем карары булачак теләгенә омтылган морза кызы булып килеп баса.

Спектакльнең җан-йөрәге булган көйләр (композитор Гөлназ Закирова, хормейстер Әнәс Фәйрушин), сәхнәдәге нәфис бизәлеш (рәссам Ләйсән Хөсәенова), Алсу Гыйльманова, Рәзил Фәхертдинов, Юлия Григорьева уенындагы рәхәт табигыйлек, күмәк күренешләрдә мәктәп укучыларының да катнашуы – болар барысы да сәхнәдә барган вакыйгаларның тәэсир көчен арттыруга хезмәт итә.

Ялган горурлык һәм ялган тәкәбберлек, ике арадагы тирән упкын мәхәббәтне юк итәргә сәләтле. Мәхәббәт белән бергә моң да үлсә, ул моңнар кабат табылырмы? Репетицияләр барышында «Хәмдия» җырына бәйле рәвештә байтак сораулар туган иде. Бүгенге заманда «моң» төшенчәсенең югалып баруы, замана җилләренең ул моңнарны тузан урынына туздырырга маташуы хакында уртага салып сөйләшү сискәндереп җибәрде. «Бакый белән бергә моң да үлеп юкка чыгармы?» дигән фикерләр булды. Спектакль азагында «Хәмдия» җырының кайтаваз булып яңгыравы исә – Мирхәйдәр Фәйзи каләме белән язылып, морза кызы теленнән: «Илнең сизгер егетләре, назлы кызлары, минем көемне җырлап, яшь җаннарын юатырлар. Исемем, телдән-телгә, буыннан-буынга күчеп, мәңге яшәр», – дип тамган сүзләрнең чагылышы иде. Татарның ачы язмышында гомер бакый тугры юлдаш булган җыр бүгенгә исән бит әле, «Хәмдия»ләр булып, моң яши бит әле бүген. Иртәгә ни булыр?..

Чаллы театры сәхнәсендәге «Ак калфак» әнә шундый сорауларга җавап эзли. Озын гомер телик үзенә.

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Көз офыгы

Көз әле алтынсу биләүдә –
Мин инде җәйләрне сагынам.
Сагышның мәйданы киңәя
Офыклар киңәйгән чагында.

Соңгы кат сөенеп калыйм, дип,
Каеннар таң белән торганнар.
Күңелгә көз моңын иңдереп,
Каңгылдый һавада торналар.

Яңгырый хушлашу авазы
Күкләрдән, таулардан – бар яктан;
...Йөрәгең өзелер бер мәлдә –
Агачтан өзелгән яфрактай.

Тик һаман кошларга ияреп
Талпына күңелем югары.
Бәхетнең үзенә илтә күк
Күктәге кошларның юллары.

Разил ВӘЛИЕВ

Укытучыга хөрмәт бар

Укытучылар һәм остазлар елы уңаеннан Балтач районында бихисап эшләр башкарылды. Укытучылар көне өлкәннәрункөнлегенә дә кергәнлектән, бәйрәм аеруча зур колач алды. Район, мәгариф җитәкчеләре пенсиядәге укытучыларны бик хөрмәтләделәр. Матур ял парклары буйлап сәяхәт иттерделәр. Үзешчәннәр башкаруында искиткеч матур концерт оештырылды.

Норма урта мәктәбе дә пенсионер укытучыларны кунакка чакырды. Кили авылы клуб мөдире Халидә Гарифуллина һәм музыкаль җитәкче Фәрит Гарифуллин бик тә эчтәлекле кичә оештырды. Пүскән, Кили башлангыч мәктәпләрендә моннан дистә ел элек укытып киткән укытучылар очраштылар. Мансура апа Ганиева, Розалия Гыйльметдинова, Рәйханә Нәҗипова, Алсу Садыйкова, Илназ Хәбибуллина моңарчы беркемгә дә сөйләмәгән серләрен ачтылар, хезмәт юллары турында сөйләделәр. Авылның яшь җырчылары катнашында кичә тагын да җанлырак, ямьлерәк булды. Һәрберебез яшьлегебезгә әйләнеп кайткан кебек булдык, яшәрдек.

«Укытучыга хөрмәт бармы?» – диләр. Бар. Бу сүзне чын йөрәктән әйтәбез. Бәйрәмдә генә түгел, ел әйләнәсе үзебез эшләп киткән коллективның җылы карашын, ихтирамын, игътибарын сизәбез. Мең рәхмәт аларга! Ә пенсионер укытучыларга үзләренең эшләгән вакытларын гел истә тотып, исәнлектә яшәргә язсын.

Розалия ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА. Балтач

ЙОЛДЫЗЛЫ КҮКТӘМЕ СИН, ӘНИЕМ?

Мин, 12 яшьлек бала, Кәримә әбиемә җәйге каникулга кунакка кайттым. Бер иртән икәүләшеп тәмләп чәй эчтек. Шул вакытта әбием:

– Кызым, бер хәбәр килде бит әле. Әниең хастаханәгә эләккән, – дип, күзләрен керфек астына яшерде.

Кайнар күз яшьләренең чәйгә тыптып тамганын сизмичә дә калдым. Әбиемне ишетмим, уемда – әнием. Бөтен теләгем – аның белән күрешү. Ләкин ара ерак, ул – шәһәрдә, мин – авылда. Берничә көн үткәч кенә, әнием янына бару бәхетенә ирештем.

Менә хастаханәнең озын коридоры буйлап әнием яткан палатаны эзләп барабыз. Керергә бик нык омтылсам да... аягым атламас булды. Палата ишеген ачтым, әниемне күреп хәйран калдым. Тәне янгында пешкән, марля белән чорнап куйганнар. Әнием, дип кочаклап, үбеп аласым килгән иде, ләкин табиблар, ярамый, диделәр. Әбием, әйдә, кызым, дип алып чыгып китте. Йөрәгемнең әрнүен берсе дә сизмәде.

Сентябрь. Мин хәзер – 7 нче сыйныф укучысы. Укырга барырга кирәк. Әнием Казан хастаханәсендә ята. Туганнар белән хәлен белергә бардык. Шатлыгым эчемә сыймый. Палатаның ишеген ачып җибәрдем. Кочаклыйсым килде, ләкин булдыра алмадым. Кагылсам, яралары тагын да көчлерәк авыртыр кебек тоелды. Хәле начарланганнан-начарлана, ләкин без яхшыга өметләндек. Әбиемнең дә укымаган догалары калмады. Әнием бик авыр сөйләшә. Алай да соңгы көчен туплап, миңа яшьле күзләре белән тутырып карады да: «Әни, кызымны карагыз, зинһар, ташламагыз», – диде. Әбием: «Ярар, борчылма, кызым, карарбыз, исән-сау терелеп кайт та үзең үстерерсең, иншалла», – дип җавап кайтарды. Әбиемә әйткән бу соңгы сүзләре һаман да колакта яңгырап тора.

...Апаларга кунарга бардым. Илүзә апам белән йокларга яттым. Аның әти-әнисе бик соң кайтты. Үзара сөйләшүләреннән әниемнең вафат булуын аңладым. Тик күңел ышанмады. Иртән торгач, апаның күзенә карадым. Алар минем сизенгәнне белмиләр бит инде. Берни булмагандай: «Тизрәк кайт», – дип озатып калдылар. Мәктәптән кайтып керүем булды: «Кызым, әниең үлде бит», – диде Әлфия апам.

Менә без авылда. Өй түрендәге караватны кыйблага таба борып куйганнар. Ә анда өстенә ак җәймә каплап куелган әнием ята. Каты итеп кочаклап алдым. Битеннән сыйпый-сыйпый, үбеп елыйм. «Әнием, син бит исән, уян инде», – дим. Ләкин ул дәшми. Капкадан алып чыгып киткәндә: «Әнием, мине калдырма», – дип артыннан кычкырып елап чаптым. Тик ул мине калдырып китте. Тормышым кара төскә керде. Әбием мине күпме генә юатырга тырышса да, булдыра алмады. Ике ай буе еладым да еладым. Укырга да бармадым.

Әниемнең фотосурәте генә калды. Үз-үземне юатып, күңелле вакыйгаларны искә алып, аның белән сөйләшәм. Авырлыкка юлыксам, киңәшләшәм. Елап та алам. Шулай фотосурәтенә карап торганда, әбием миңа: «Елама, кызым, тукта, әниеңне суга саласың бит», – диде. Шул көннән үз-үземне кулга алырга тырыштым. Әбием белән бергә яшәдек. Ул мине нык булырга өйрәтте. 11 нче сыйныфны тәмамлап, институтка кердем. Әнием кебек тәрбияче, укытучы буласым килде. Институтны тәмамладым. Кияүгә чыктым. Ринатым тормышымның иң зур бүләге булды. Аның белән өч кыз – Алинә, Зәринә, Ралинәне үстерәбез. Сине исән килеш күрмәсәләр дә, беләләр, яраталар, әнием. Вафатыңа инде егерме өч ел үтсә дә, күңел һаман ышанмый. Каядыр киткән кебек тоеласың, кайтырсың дип көтәм. Бик сагынам. Йолдызлы күккә карыйм да, аннан, елмаеп, миңа күз сирписең сыман тоела. Тыныч йокла, кадерле әнием!

Рузилә ӘБРАРОВА

КАЛҖАЛЫ ЧОР

Җәен тозлы иттән аш-су әзерләп, көзен коры ризык пешереп, майлы калҗага сусаган халык кышның чатнама салкыннарын зарыгып көтеп ала иде. Җиргә ак кар ятып, елгаларда боз катуга, элек-электән авылларда каз өмәләре гөрләде. Өмәдән соң, каз маена батырып, ачыга коймак кыздыралар, тары ярмасыннан ботка пешерәләр иде бездә.

Әлбәттә, терлек чалу – җаваплы, җитди эш. Билгеле бер кагыйдәләрне исәпкә алу кирәк. Бу эшкә теләсә кемне чакырмыйлар, авылның осталары, аксакаллары җыела. Эре малны куркытмыйча, сукмыйча, тартмыйча, сүгенмичә хәстәрләп, җайлап сул ягына салыр өчен киң бәдәнле, калку дүртбиш ир-ат та кирәк.

Эчәкләрен эшкәртергә, ир-егет артыннан алгалап-җыйгалап торырга хатын-кыз, бала-чага комганда, чиләктә җылы суын, коры чүпрәген тотып, әзер тора. Ир-атлар, сугымлык яныннан читкәрәк илтеп, малның эчәк-карынын чыгарып салалар. Балалар да, хатын-кызлар белән беррәттән, дәррәү килеп, эчәк эшкәртергә керешәләр. Арада өлкәнрәге, тәҗрибәлерәге эчәкләрне тишмичә, ашыкмыйча, җайлап кына эч майларын кисеп алырга тиеш. Гадәттә ул эшләрне өмәгә чакырылган берәр апа эшли. Әни – оештыручы. Берсен китерә, икенчесен алып китә, кыскасы, ир-атлар белән хатын-кызлар арасында йөгергәләп тора. Ул арада җыеп алган майны зур табакларга салып, эретергә дип, газ өстенә утыртып куя. Туңмайны кыш буе аш-су әзерләргә кулланалар, май сызыгын бәрәңге кыздырганда кушалар иде.

Күмәк кулга эш тотмас, диләр бит. Апа берәр ярдәмчесе белән комганга салган җылы суны күпләп агызып, эчәкләрне бер кат юдырып ала. Сугымлык малны чаласы көн алдыннан ашатмый-эчертми торсалар да, үзегез беләсез, эчәкләрне чистартыр өчен бик күп вакыт һәм тырышлык кирәк. Менә монда балаларга аякларын аямыйча таптанырга туры килә инде. Бер кат чистарткан эчәкләрне апалар, ярып, ак кар өстенә ата торалар, без итеккә кәлүш кигереп алабыз да (сүчинкә дип йөртәләр аны безнең якта), мәш килеп, әледән-әле урынын алыштырып, эчәк таптарга тотынабыз. Кар өсте буялып бетә. Аннары әниләр аны ун литрлы чиләкләргә салып, авырлыктан менә-менә сынарга торган көянтәгә эләктереп, сыгыла-бөгелә, атлый-йөгерә, су буена төшеп китәләр. Без дә ияреп төшәбез, чөнки еш кына, әниләр ялангач куллары белән боз ярып салкын суда чайкаганнан соң да бик чиста булмаган эчәкләрне сөзәк яр буендагы кар өстенә ата торалар, безгә һаман да бер эш – ярыша-ярыша эчәк таптыйбыз. Эчәк-картаның бер сырында да бернинди ризык калдыгы булмаска тиеш. Алайса, ничек ашыйсың ди аны! Соңыннан алсуланып торган эчәкләрне зур булмаган өлешләргә аерып бәйләп, чолан матчасына элеп куялар иде. Ул заманда әниләр бер генә нәрсәне дә исраф итмиләр иде бит. Тырышлык белән тапкан ризык бигрәк кадерле, тәмле булган. Эчәктән мичтә пешкән бәрәңге бөккәненең тәме әле дә авызда тора.

Мал суюның эше шактый булса да, өмә итеп үткәргәч, аның мәшәкате артык сизелми иде кебек. Чалырга күрше Илһам абый һәвәс иде. Әтинең сугымда гына кузгатыла торган, алдан әзерләп, үткенләп куелган пычаклары бар. Аларны сугымга дигән җан иясенә күрсәтеп чарларга, үткенләргә ярамый. Шуңа алдан әзерләп куялар.

Шул малларны үлеп кызгана идем мин. Бер мәлне сугымга дигән сыерның күзеннән яшь агып төшкәнен күреп исем китте. Аңлый икән бит ул үзен ни көткәнен! Бу күренеш күңелемә кереп калды. Шуңадыр инде, вакыт-вакыт ит ризыкларын ашамый да торам. Кечкенәдән кисәкләп ашап утырганымны хәтерләмим. Алай да бәлеш, өчпочмак, мантый, пилмәннән ничек баш тартасың ди инде?

Сугым вакытында авылларда бәйрәм, өмә, кичке аш башлана иде. Зур табыннар җыеп, туган-тумача, күрше-күлән, дус-иш очрашып, табын янында, гармунга кушылып, җырлап утыралар. Шуларны күреп үскәч, ничек җыр-моңга гашыйк булмыйсың инде! Ул моң хатирәләр белән бергә минем күңелемә сеңеп калган, күрәсең.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА. Казан

Авылча яшәп ятыш

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Бу рубрика сезнең күңелләргә бигрәк тә хуш килер, мөгаен. Сез ниләр майтарып ятасыз? Нинди яңалыклар бар? Языгыз әле безгә. Башкалар белән дә уртаклашыйк.

Арча, Ташкичү

Игелекнең чиге юк

Менә тагын күпме ярдәм җыелды. Безнең якта халык искиткеч ярдәмчел, бердәм, тату, бар эштә дә актив катнашалар. Халык әйтемендәгечә, «бер якадан баш чыгарып», бергәләп, ярдәмләшеп, киңәшләшеп эшлибез без. Бу юлы да кием-салым, азык-төлек күп җыелды, ә акчага икмәк алып тапшырдык. Приютта бик зур рәхмәт әйтеп калдылар. Кадерле дуслар, барыгызга да зур рәхмәт, Аллаһ сәламәтлегегездән аермасын, мохтаҗлык күрсәтмәсен, бергә булыйк, бердәм булыйк!

Туган як җылысы

Бүген без Казанга, «Ценим жизнь» исемле волонтерлар оешмасына бардык. Бигрәкләр дә ачык йөзле, мөлаем, эшчән, ярдәмчел кешеләр эшли икән анда. Үз теләкләре белән бушка илебезнең тынычлыгы өчен хезмәт итүче егетләребезгә башлык, шарф һәм җылы кофталар, үзләре белән йөртерлек җайлы сумкалар (эченә медицина кирәк-яраклары тутырылган) тегәләр һәм иң дулкынландырганы – шул әйберләрне ике атна саен үзләре илтеп тапшыралар да икән. Кем дә кем безнең җибәргән әйберләребез барып җитәрме икән дип шикләнсә, шул оешмага илтеп тапшыра алалар. Барлык гамәлләре турында тыныч кына аңлаттылар, күрсәттеләр. Медицина кирәк-яраклары тутырылган сумкада ни генә юк! Хәтта үзләре кадый алырлык шприц та бар. Элегрәк ул сына торган булган, ә хәзер саклагыч эшләп бирүче волонтер табылган, аның өчен бик сөенгәннәр. Их, шундый изге күңелле, ярдәмчел кешеләребез күбрәк булсын, барлык әйберләр дә егетләребезгә барып җитеп, туган як җылысын тоеп йөрсеннәр, тизрәк әйләнеп кайта күрсеннәр иде.

Гөлфия МӘГЪСҮМОВА

Елга порты елата

Казанның биш диңгез порты икәнен белмәгән кеше юктыр, мөгаен. Казан елга порты Ак, Балтыйк, Кара, Азов һәм Каспий диңгезләрен тоташтыра. Бу аның Россиядә мөһим транспорт юлы икәнлеген ассызыклый. Казан елга порты пассажирларга да хезмәт күрсәтә, йөк йөртү белән дә шөгыльләнә. Әмма андагы хәлләр инде берничә ел буена Казан шәһәрен бер дә бизәми. Килгән-киткән кеше бик гаҗәпләнә моңа.

Бик матур кояшлы көн иде. Мин дә туганнарымны каршы алырга портка юнәлдем. Беренче күзгә ташланган әйбер – аның ташландык, пычрак хәлдә булуы. Ачык тәрәзәләр күренә, эчтә бушлык, ишек тоткалары пәрәвезгә уралган. Тышкы яктагы баскычларны, бина тирәсендәге нигезләрне чүп үлән баскан. Тирә-якта буш шешәләр, чүп тутырылган ертык капчыклар, хәтта үлгән күселәр аунап ята. Күңелгә тия торган әйберләр тагын да бихисап әле. Елга порты бинасының диварларында мәгълүмат язылган ике элмә такта бар. Берсе – Девятаев урамы, 1 нче йорт дигән күрсәткеч, икенчесе – Советлар Союзы Герое Девятаев хөрмәтенә куелган мемориаль такта һәм ул әйткән канатлы сүзләр – «Теләсә нинди, хәтта тормышта килеп туган иң авыр хәлдән дә чыгу юлы бар». Бу сүзләр өч телдә язылган.

Мәгълүмат чараларыннан белешкән идем: елга портын торгызырга, биләмәсен тәртипкә китерергә планлаштыралар икән. Территориянең бер өлеше Татарстан Республикасы флотына тапшырылачак, ди. Әмма әлегә Казан порты безне оятка калдыруын дәвам иттерә. Совет вакытында Казан порты Идел ярындагы иң яхшы урыннарның берсе иде. Аңлыйм инде, барысы өчен дә финанс ягын кайгыртырга кирәк. Тик күп кирәкми бит: тәртиптә һәм чисталыкта тоту өчен бер җыештыручы да җитәр иде.

Рәис МИҢНУЛЛИН



Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сораугa җавап эзли.

ТАТАР

ЙОЛДЫЗЛЫ АЛАЧЫК

Казан

Җырчы, Татарстанның атказанган артисты Чулпан Әхмәтҗанованың концерт афишасына язылган шушы сүзләрне баш исем итеп алуым юкка гына түгел. Мөгаен, ул Чулпанның үз исеменә бәйледер инде. Ә минем бу алачыкта этиләре Шамил абыйны хуҗа итеп күреп, тагын «җырлы-моңлы» дигән сүзләрне дә өстәп куясым килде. Сәнгать дөньясында900 бербөтен булып яши бу гаилә. Әмма бүген без, проект шартларына туры китереп, татар теле, татар дөньясы турында сөйләштек.

«Ярый, башка әйтмәм»

Шамил абый белән Рәзилә апа, бала туган телне өйрәнсен өчен, беренче чиратта гаиләдә тиешле мохит тудырырга кирәк дигән фикердә.

– Бервакыт шулай балалар бакчасына Чулпанны алырга бардым, – дип искә ала Шамил абый. – Кызым йөгерә-сикерә кайтып барган җиреннән миңа борылды да «папа» дип эндәште. Әллә ничек имәнеп киттем шунда. «Абау, кызым миңа «поп» дип эндәште. Мин нинди поп булыйм инде?» – дип уенга борган булдым. «Бакчада бөтен кеше этиләренә «папа» дип әйтә бит», – ди кызым. «Аларныкы пападыр, синеке эти белән әни, чөнки без – татарлар», – дип, матур гына аңлаттым. Шуннан: «Ярый, эти, башка әйтмәм», – диде. Бу хатирәне ник сөйлимме? Баланы вакытында кисәтергә кирәк. Әрләп, тавыш күтәреп, вәгазь укып түгел, сабыр гына, тыныч кына аңлату дөрес. Телне, гореф-гадәтләрне саклап калу ниятеннән күрер күзгә гади генә тоелган күп әйберне кулланырга була инде ул. Мәсәлән, без балаларга кечкенәдән догалар өйрәттек. Өстәл яныннан киткәндә, битләрен сыпырып, эти-әнигә дә, Ходайга да рәхмәт әйтеп китү алар өчен гадәти күренеш иде. Бу яктан Рәзилә апаң да бик таләпчән булды. Урамга оныкларны ияртеп чыкса, ялгыш кына да бер русча сүз ычкындырмады. Тирә-күршедәге татарлар русча дәшсә дә, татарча җавап бирде. Үсә төшкәч, сөйләшүләр дә башкачарак булды, әлбәттә. «Тиздән гаилә корырга да вакыт җитәр. Минем өемә «бактерия» алып керә күрмәгез», – дип гел әйтә килдем.

Нәрсә икән бу дип аптырый күрмәгез. Шамил абый халык күңелен телгәли торган татар халык җырларын башкарганда бик җитди күренсә дә, бик тә җор телле. Бу очракта кияүләр дә үзебезнеке булсын, оныклар да туган телдә рәхәтләнеп сөйләшсен дип әйтүе аның. Хәер, ул яктан гаиләдә бернинди хилафлык юк. Барысы да Шамил абый белән Рәзилә апа теләгәнчә. Кияүләре – ике Рамил, оныклары Камилә, Мәликә, Ясминә, Әминә – барысы да туган телдә сөйләшә. Бу җәһәттән Шамил абый кияү турында да бер кыйсса сөйләп алды.

– Бервакыт шулай Рамил Гөлнар кызымның кулын сорарга килде. Күзәтәм инде. «Исәнмесез» дип матур гына исәнләшеп керде. Чәй эчәргә утырдык. Өстәл яныннан торганда битен сыпырып, рәхмәт әйтте. Шунда: «Безнең кеше икән», – дип җиңел сулап куйдым. Мине булачак кияүнең торыр урыны да, машинасы да, башка байлыгы да кызыксындырмый иде инде. Чыннан да, беренче көннән үк уртак тел табып яши башладык. Хәзер мәчеткә дә йөри.

Баланың баласы балдан татлы.

Милләтпәрвәр

– Милләтче сүзе бездә дөрес мәгънәдә кулланылмый. Туган телемне, гореф-гадәтләремне яратам, аларны саклар өчен җанымны-тәнемне бирәм икән, димәк, мин начар кеше түгел бит инде, чын мәгънәсендә милләтпәрвәр, – дип фәлсәфәгә бирелеп китте Шамил абый. – Минем фикердәшләрем дә бар. Бервакыт шулай телевизордан бер тапшыру караган идем. Алып баручының фамилиясе истә калмаган. Ә менә үзе бик дөрес сүзләр сөйләде. «Милләтче ул куркыныч кеше түгел. Ул – үзенең телен, гореф-гадәтләрен, халкын, милләтен ярата торган кеше», – диде. Мин бу сүзләр белән тулысынча килешәм. Үзем дә гел татар җырларын гына җырладым. Кирәк булганга түгел, күңелем шулай кушты. Дөрес, рус телендә «Родина» дигән җырны бик яратып җырлый идем. Анда «Люблю Украину, люблю Кавказские горы» дигән сүзләр бар. Бүгенге вазгыятьтә җырларга тел әйләнми.

Үтемле тел

«Татар теле нигә кирәк ул?» – дигәннәрен минем дә күп ишеткәнем бар. Аларга Туфан Миңнуллин сүзләре белән җавап биргәлим. Бервакыт аңа да шундый сорау биргәннәр. Ул: «Менә синең кебек хайваннарга «хайван» дип әйтер өчен кирәк», – дигән.

И-и, аңлаган кешегә телебезнең бөеклеге әйтеп бетерә алмаслык бит ул! Мин Урта Азиянең бөтен республикаларында, илләрендә диярлек гастрольләрдә йөрдем. Кайда гына булсам да, таҗиклардан кала, барысы белән дә рәхәтләнеп аралаштым. Барлык тугандаш халыкларның җырларын өйрәндем. Үз телләрендә җырлагач, кочак җәеп каршы алдылар. Мондый мөнәсәбәтләр динем белән дә бәйле булды. Гарәп илләренә дә күп йөрдек. Анда да туганнар кебек булдык.

> Телебезне зәгыйфьләндермисе иде. Агачны да бит, бер зәгыйфьләнгәч, элеккеге хәленә кайтару бик авыр. Ул барыбер гарип булып кала.

Телне яхшы белү ул мәктәптә ничек укытуга да бәйле. Мин татар теле укытучысын бүген дә зур хөрмәт белән искә алам. Ихластан укыттылар чөнки. Шул туган телемне әйбәт белү аркасында, күпме кеше белән аралашу бәхетенә ия булдым. Кулыма каләм тотып яза алдым. Сибгат ага Хәким: «Синең язмаларны бик яратып укыйм. Ноктaлы өтерләреңә кадәр дөрес куясың бит син. Туплап бар. Китап итеп чыгарырга ярдәм итәрмен», – ди иде. Өлгерә алмый калдык.

Чулпан Әхмәтҗанова гаиләсе.

Оясында ни күрсә...

Тапталган дип кабул ителсә дә, бу сүзләр Әхмәтҗановлар гаиләсенә бик туры килеп тора. Чулпан Казан дәүләт педагогия институтының музыка факультетын тәмамлаган. Матур җырлары белән газиз халкын сөендерә. Хәзер ул этисе юлында: Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә хормейстер булып эшли. Шамил абый шушы ансамбльгә 55 ел гомерен биргән.

– Гөлнарны да чакыралар, – ди ул. – Тик ул башка һөнәрләрне дә үз итә. Шулай да музыка өлкәсен ташлап бетерми. Ансамбльнең юбилее уңаеннан «Рәйхан» дигән җырны әзерләргә тотынган идем. Чулпан белән икәү эшкәртеп бирделәр. Оныклар да сәнгать дөньясын яратып, төрле музыка коралларында уйнарга өйрәнеп үстеләр. Әмма заманасына күрәдер инде, башка һөнәрләргә тартылдылар. Камилә КФУның чит телләр факультетында укыды. Татар, рус, төрек, француз, инглиз телләрен камил белә. Әлегә Төркиягә китеп барды. Мәликә химия-технология институты каршындагы техникумны тәмамлады. Ясминә «Адымнар» мәктәбендә 11 нче сыйныфта укый. Чулпан кызы Әминәгә 4 яшь кенә әле. Күбрәк безнең янда әвәрә килә. «Туган тел» җырын бик ошата. Безнең бүлмәгә: «Әй Зәлилә, Зәлилә, иртә белән чиләк асып, суга бара Рәзилә», – дип җырлап килеп керә дә әбисен кочаклап ала. Әбисе Рәзилә исемле бит. Имеш, күңелен күрә. Шундый шаян җырларны өйрәтеп кенә торам. Исемле булгач, кемгәдер багышлангач, тизрәк тә, яратыбрак та ятлый.

Исем дигәннән, яңа туган балаларга әллә нинди нинди... диләрен кушалар хәзер. Бервакыт шулай Кирам Сатиевның сөйләгәне истә калган: «Бездә Робсон, Трактор, Штурвал кебек исемнәр бар», – дигән иде ул. Үзебезнекеләргә җитәме соң! Татар телен саклау шуннан башлана түгелме соң инде? Әби-бабайлар да читтән карап тормасыннар иде бу гамәлгә. Оныкларыма исемнәрне үзем куштым дияргә була. Дөресрәге, мин тәкъдим иттем, кызларым-кияүләрем каршы килмәде.

ВИДЕО

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ/
Гаилә архивыннан

Шамил абый истәлекләре

«Сәгатеңә карама әле»

Ничектер шулай, Минтимер ага Шәймиев белән берничә тапкыр сөйләшеп утырырга туры килде. Рәсми очрашу түгел иде ул. Хәзер инде ничек килеп чыкканын бик хәтерләмим. Берсендә сөйләшү озаккарак сузылды. Эчемнән генә: «Китәргә кирәк инде. Эш кешесенең вакытын алып утырам», – дип кыбырсына башладым. Вакыт-вакыт сәгатемә карап алам. Шунда Минтимер Шәрипович: «Шамил, карама әле шул сәгатеңә. Рәхәтләнеп саф ана телендә сөйләшеп утырыйк әле», – дип кисәтү ясады. Ул мине «кияү» дип йөртә иде. Чөнки хәләл җефетем Рәзилә – Актанышныкы.

«Җибәрмәсәгез, җырламыйм»

Төркиягә концерт куярга чакырдылар. Конья дигән шәһәрдә төрекчә дә, татарча да, казахча да, кыргызча да җырлыйм. Шулай беркөнне берәү килде дә кунакка чакыра. Шушы шәһәрдән ерак түгел татар авылы бар икән. Әби-бабайлары кайчандыр Татарстаннан күченеп килгән. Үзләре төрекләшкән инде, әмма татар җанлы булып калганнар. Шуннан килгән милләттәшем булып чыкты бу. «Хуҗадан сорап кил инде», – дип, концертны оештырган төрек кешесе янына җибәрдем. Килә бу, рөхсәт итмәгәннәр. Үзем бардым да: «Әгәр мине милләттәшләрем янына җибәрмәсәгез, мин башка концертларда төрек җырын җырламыйм», – дидем. Сүзсез калдылар. Шундук ризалаштылар. Бу очракта «милләттәш» сүзе үз ролен үтәде.

Бу – Әхмәтҗановлар гаиләсендә иң кадерле фотоларның берсе. Балалар үсеп җиткән, гаиләнең тулы, иң бәхетле чагы. Кайгы көтмәгәндә килә. Уллары Илдар, 23 яшендә машина астында калып, фаҗигале төстә һәлак була. «Шуннан соң бер ел халык каршына басып җырлый алмадым, – ди Шамил абый. – Соңрак аңладым инде, бирешмәскә кирәк булган. Җыр-моң үзе ярдәм итәр иде. Әмма үзәк өзгеч бу кайгыдан арынырлык чамам булмаган, күрәсең».

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 341

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+